187. «Ә.М. Гыйльметдинованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........ 234

188. «Н.Г. Залетованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........ 234

189. «В.А. Тимофеевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........ 235

190. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Ә. Гаделшин, А.Ф. Шәрипова тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 579-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау турында (Татарстан Республикасының дәүләт милке объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........ 235

191. «И.Ә. Бәешеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........ 236

192. «Р.Ф. Сафинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........ 236

193. «Э.Ә. Ганиевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турын-

да» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................ 237

194. «Н.А. Головановны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................ 237

195. «З.Х. Гыйззәтуллинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................... 238

196. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Ф. Шәрипова тарафыннан кертелгән «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 581-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (физик затлар булган салым түләүчеләр тарафыннан салым түләү срокларын үзгәртү өлешендә) алдан карау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................... 238

197. «И.Ю. Ермолаеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................ 239

198. «Г.Г. Хәйруллинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................ 239

199. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.М. Захарова, В.П. Логинов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 580-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү шартларын төгәлләштерү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* .................................................. 240



200. «Т.А. Сәхибуллинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................... 241

201. «Л.С. Ильченконы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ........................................................................ 241

202. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 582-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын («Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» дәүләт программасын гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләрен яңадан бүлү өлешендә) алдан карау хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе* ..................................................... 242

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Мамадыш суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» 2010 елның 31 декабрендәге 119-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче суд участогы чикләрен тасвирлауның икенче абзацында «Малмыж,» сүзен төшереп калдырырга;

2) 2 нче суд участогы чикләрен тасвирлауның икенче абзацында «Дегетле,», «Керәшен Пакшины,», «Рагозино, Сикәнәс,» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Актаныш суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» 2010 елның 31 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче суд участогы чикләрен тасвирлаудан «, Чишмә» сүзен төшереп калдырырга;

2) 2 нче суд участогы чикләрен тасвирлаудан «Яңа Кормаш» сүзләрен төшереп калдырырга.



**3 статья**

«Татарстан Республикасы Биектау суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» 2010 елның 31 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче суд участогы чикләрен тасвирлаудан «Пермяк, Сосновка,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 нче суд участогы чикләрен тасвирлауда «, Чернышевка, Чыршы һәм Шуман» сүзләрен «һәм Чернышевка» сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

«Татарстан Республикасы Зеленодольск суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» 2011 елның 1 августындагы 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), 8 нче суд участогы чикләрен тасвирлаудан «Олы Ходяш,», «Мизиново,» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 13 гыйнвары
№ 1-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 2. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 3; 2013, № 1, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның сигезенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 15 статьяның 12 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 18 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:
«$1^1$. Җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре яисә бүтән эшләр башкарганда табылган археологик предметларны күрсәтелгән эшләрне башкаручы физик һәм (яисә) юридик затлар мәдәни мирас объектларын саклау буенча федераль орган билгеләгән тәртиптә мәҗбүри рәвештә дәүләткә тапшырырга тиеш.»;
б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:
«$2^1$. Табылган археологик мирас объекты турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» Федераль законның $45^1$ статьясындагы 11 пунктында каралган мәгълүмат Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органына кергән көннән соң утыз көн эчендә археологик мирас объекты табылган җир кишәрлеге милекчесенә һәм (яисә) җир кишәрлегеннән файдаланучыга, территориясендә әлеге археологик мирас объекты табылган муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органына җибәрә.»;



4) 35 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Тарихи-мәдәни терәк план документлаштырылган һәм автоматлаштырылган рәвештә Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестры белешмәләре, тарихи-мәдәни тикшеренүләр материаллары, тарихи-архитектура терәк планнары һәм мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавына, аларны саклап калуга һәм алардан файдалануга караган башка белешмәләр нигезендә Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы тарафыннан төзелә һәм алып барыла.»;

5) 36 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 37 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:
«4. Археологик мирас объектын физик саклап калуны тәэмин итү мөмкин булмаган очракта, бу археологик мирас объектын саклап калу дигәндә «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» Федераль законның $45^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә казылмалардан археологик предметларны тулысынча яисә өлешчә алып уздырыла торган коткару буенча археологик кыр эшләре аңлашыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 13 гыйнвары
№ 2-ТРЗ

## 3. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 5 пунктында «көч куллануны» сүзләреннән соң «, рәсми спорт ярышлары нәтиҗәләренә хокукка каршы йогынтыны» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяда:
а) 2 пунктта «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;
б) 6 пунктта «(спорт командалары),» сүзләреннән соң «тамашачылар,» сүзен өстәргә;

3) 6 статьяның 1 өлешендәге 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8) физик культура һәм спорт өлкәсендә кадрлар әзерләүне һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;»;

4) 12 статьяда:
а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Физкультура чараларын яисә спорт чараларын оештыручылар аларны уздыру шартларын, шул исәптән спорт судьяларына спорт ярышларында катнашу өчен алар тарафыннан алына торган туклану, спорт җайланмасы, җиһазы, спорт һәм парад формасы хакын түләүгә бәйле компенсация түләүләрен бирү шартларын һәм тәртибен билгели, мондый чараларны оештыру һәм уздыру өчен җаваплы була, мондый чараларны туктатып торырга һәм туктатырга, аларны уздыру вакытын үзгәртергә һәм аларның йомгакларын расларга хокуклы, шулай ук рәсми спорт ярышлары уздырганда спорт объектлары милекчеләре, спорт объектларыннан файдаланучылар



белән берлектә җәмәгать тәртибе һәм иҗтимагый иминлек чараларын Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган рәсми спорт ярышлары уздырганда иминлекне тәэмин итү кагыйдәләре (алга таба – рәсми спорт ярышлары уздырганда иминлекне тәэмин итү кагыйдәләре) нигезендә тәэмин итә. Рәсми спорт ярышлары уздырганда җәмәгать тәртибе һәм иҗтимагый иминлек чараларын тәэмин итү, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, рәсми спорт ярышлары турында нигезләмәләр (регламентлар) һәм (яисә) мондый ярышларны оештыручылар һәм спорт объектлары милекчеләре, спорт объектларыннан файдаланучылар арасында төзелгән шартнамәләр нигезендә рәсми спорт ярышларын оештыручылар һәм (яисә) спорт объектлары милекчеләре, спорт объектларыннан файдаланучылар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. Рәсми спорт ярышлары уздырганда җәмәгать тәртибе һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итү буенча рәсми спорт ярышларын оештыручыларның, спорт объектлары милекчеләренең, спорт объектларыннан файдаланучыларның хокуклары һәм бурычлары Федераль закон, шулай ук рәсми спорт ярышлары уздырганда иминлекне тәэмин итү кагыйдәләре белән билгеләнә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^2$ өлеш өстәргә:
«$1^2$. Рәсми спорт ярышлары уздырганда тамашачыларның хокуклары һәм бурычлары, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылык, шулай ук рәсми спорт ярышларын уздыруны оештыручыларның, спорт объектлары милекчеләренең, спорт объектларыннан файдаланучыларның, контролер-эш йөртүчеләрнең хокуклары һәм бурычлары федераль законнар нигезендә билгеләнә.»;
в) 4 өлештә «махсус» сүзен төшереп калдырырга;

5) түбәндәге эчтәлекле $12^1$ статья өстәргә:
«$12^1$ статья. **Физкультура чараларын яисә спорт чараларын оештыруга һәм уздыруга бәйле намуслы конкуренция тәэмин итү**
Физкультура чараларын яисә спорт чараларын оештыруга һәм уздыруга бәйле намуслы конкуренция тәэмин итү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

6) түбәндәге эчтәлекле $17^1$ статья өстәргә:
«$17^1$ статья. **Рәсми спорт ярышлары нәтиҗәләренә хокукка каршы йогынтыны булдырмау һәм аңа каршы көрәш**
Рәсми спорт ярышлары нәтиҗәләренә хокукка каршы йогынтыны булдырмау һәм аңа каршы көрәш федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

7) 18 статьяның 4 өлешендә «мәгариф учреждениесенә» сүзләрен «мәгариф оешмасына» сүзләренә алмаштырырга;

8) 19 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Мәгариф оешмалары, җирле шартларны һәм укучыларның мәнфәгатьләрен исәпкә алып, физик культура дәресләре рәвешләрен, физик тәрбия чараларын, спорт һәм актив хәрәкәт төрләрен, физик культура дәресләре ысулларын һәм дәвамлылыгын федераль дәүләт мәгариф стандартлары һәм физик әзерлек нормативлары нигезендә мөстәкыйль билгели.»;

б) 2 өлештә:

беренче абзацта «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) төп белем бирү программалары чикләрендә физик культура һәм спорт буенча мәҗбүри дәресләр, шулай ук өстәмә гомуми белем бирү программалары чикләрендә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү буенча өстәмә (факультатив) дәресләр уздыру;»;

түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10) укучыларның халыкара спорт чараларында, шул исәптән Бөтендөнья универсиадаларында һәм рәсми спорт ярышларында катнашуы.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Укучыларны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең, урта һөнәри һәм югары белемнең белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары һәм (яисә) мондый оешмаларның укучылары тарафыннан мәктәп спортын, студентлар спортын үстерү һәм популярлаштыру максатларында юридик затлар булмаган мәктәп спорт клублары һәм студентлар спорт клублары (шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр төрендә) төзелергә мөмкин. Мондый спорт клублары эшчәнлеге федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

9) 22 статьяда:

а) 5 өлештә «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;

б) 7 өлештә «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;



10) 24 статьяның 1 өлешендә «физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләре, физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре» сүзләрен «физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы балаларга өстәмә белем бирү оешмалары, физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

11) 27 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

«$6^1$. Рәсми спорт ярышлары уздыру өчен кулланыла торган спорт объектларының милекчеләре, спорт объектларыннан файдаланучылар мондый ярышлар уздырыла торган урыннарны тамашачыларның керү билетлары яисә аларны алмаштыра торган документларның булу-булмавын тикшерергә мөмкинлек бирә торган тиешенчә техник җиһазлауны тәэмин итә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 9 һәм 10 өлешләр өстәргә:

«9. Рәсми спорт ярышлары уздырганда иминлекне тәэмин итү кагыйдәләре нигезендә рәсми спорт ярышлары уздыру урыннарында кирәкле инфраструктура, физик затлар рәсми спорт ярышлары уздыру урыннарында булган вакытта аларны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган видеокүзәтү системалары һәм техник җиһазлар булырга тиеш.

10. Рәсми спорт ярышлары уздыру өчен кулланыла торган спорт объектлары милекчеләренең, спорт объектларыннан файдаланучыларның бурычлары Федераль закон белән билгеләнә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статья белән үз көчләренә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктның «б» пунктчасы, 4 пункттагы «а», «б» пунктчалары, 11 пункты 2014 елның 20 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1, 6 пунктлары 2014 елның 21 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 18 гыйнвары
№ 3-ТРЗ

## 4. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү һәм «Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендаланучы биналар мәйданының иң чик күрсәткечләрен һәм сатып алына торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп тору срогын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 3 өлешнең 2 пунктында «һәм муниципальара» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 5 өлештә «һәм муниципальара» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 4 статьяда:

а) 2 өлештә:

2 пунктта «һәм муниципальара» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «республика һәм муниципальара дәрәҗәдә» сүзләрен «республика дәрәҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «һәм муниципальара» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 өлештә «, муниципальара» сүзен төшереп калдырырга;



г) 5 өлештә «һәм муниципальара» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 8 статьяда:

а) 1 өлештә «консультация үзәкләрен» сүзләреннән соң «, сәнәгать паркларын, индустрия паркларын, агросәнәгать паркларын, технологияләрне коммерциальләштерү үзәкләрен, югары технологияле җайланмалардан күмәк файдалану үзәкләрен, инжиниринг үзәкләрен, прототиплаштыру һәм сәнәгать дизайны үзәкләрен, технологияләрне трансферлау үзәкләрен, кластер үсеше үзәкләрен, эшчәнлекләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра торган фәнни, фәнни-техник, инновация эшчәнлеге үзәкләренә ярдәм итүче дәүләт фондларын» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерә торган оешмаларга таләпләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү буенча республика программаларын һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.»;

4) 9 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пунктында «, муниципальара» сүзен төшереп калдырырга;

б) 4 өлешнең 1 пунктында «, муниципальара» сүзен төшереп калдырырга;

5) 10 статьяда:

а) 1 өлештә «, муниципальара» сүзен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «, муниципальара» сүзен төшереп калдырырга;

6) 12 статьяның 6 өлешендә «һәм муниципаль» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 13 статьяда:

а) 1 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга (әлеге Законның 8 статьясында күрсәтелгән, эшчәнлекләрен дәүләт учреждениеләре рәвешендә гамәлгә ашыручы фәнни, фәнни-техник, инновация эшчәнлеге үзәкләреннән тыш) мөлкәти ярдәм дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне, шул исәптән җир кишәрлекләрен,

биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне, торак булмаган урыннарны, җиһазларны, машиналарны, механизмнарны, җайланмаларны, транспорт чараларын, инвентарьны, инструментларны, биләүгә һәм (яисә) файдалануга түләүле нигездә, түләүсез нигездә яисә ташламалы шартларда тапшыру рәвешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү буенча республика программалары һәм муниципаль программалар нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

б) 2 өлешкә «, моңа мондый мөлкәтне «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы $2^1$ өлеше нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә түләүле рәвештә читләштерү керми» сүзләрен өстәргә;

в) 4 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт күчемсез мөлкәте (җир кишәрлекләрен дә кертеп), Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән сатып алына торган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән җайланмалар һәм бүтән күчемле мөлкәт, шулай ук «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы $2^1$ өлеше нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә түләүле рәвештә читләштерелгән мөлкәт исемлеген формалаштыра һәм раслый. Әлеге исемлек массакүләм мәгълүмат чараларында һичшиксез бастырып чыгарылырга, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шуны раслаган органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация



челтәрендәге рәсми сайтында һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтүнең рәсми сайтларында урнаштырылырга тиеш;»;

8) 15 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында «мәгълүмат системаларын,» сүзләреннән соң «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтүнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын,» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Мәгълүмат системалары, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтүнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтлары һәм белешмәләр банклары кече һәм урта эшкуарлык субъектларын, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларны түбәндәге мәгълүмат белән тәэмин итү максатларында төзелә:

1) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү буенча федераль программаларны, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү буенча республика программаларын, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү буенча муниципаль программаларны гамәлгә ашыру турында;

2) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны һәм икътисадый эшчәнлек төрләре буенча аларның классификациясе турында;

3) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының икътисадый эшчәнлек төрләре классификациясе нигезендә аларда биләнгән эш урыннары саны турында;

4) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының икътисадый эшчәнлек төрләре классификациясе нигезендә алар җитештерә торган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) әйләнеше турында;

5) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының финанс-икътисадый хәле турында;

6) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар, мондый оешмаларның кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү шартлары һәм тәртибе турында;

7) әлеге Законның 13 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән дәүләт мөлкәте турында;

8) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын

барлыкка китерүче оешмаларга финанс ярдәме күрсәтүгә игълан ителгән конкурслар турында;

9) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү өчен кирәкле башка (икътисадый, хокукый мәгълүмат, статистика, җитештерү-технология мәгълүматы, маркетинг өлкәсендәге мәгълүмат) мәгълүмат белән.»;

в) 4 өлешкә «рәсми сайтларында» сүзләреннән соң «һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмат ярдәме күрсәтүнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге органнар тарафыннан төзелгән рәсми сайтларында» сүзләрен өстәргә;

9) 20 статьяның 3 пунктында «, муниципальара» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон үз көченә кергән көннән «Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендаланучы биналар мәйданының иң чик күрсәткечләрен һәм сатып алына торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп тору срогын билгеләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон, 2014 елның 1 июленнән үз көченә керә торган 1 статьясындагы 3 пунктының «б» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 20 гыйнвары
№ 4-ТРЗ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 5. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 маендагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 5; 2009, № 6; 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) тугызынчы абзацта «һөнәри белем бирү учреждениеләренең» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмаларының» сүзләренә алмаштырырга;

б) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләрендә, мәгариф оешмаларында, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда тәрбия эшенең төрле рәвешләренә ярдәм итү һәм аларны үстерү;»;

2) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә дәүләт ярдәме**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә законнар нигезендә ярдәм күрсәтәләр.

Федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән түбәндәгеләргә әлеге Закон нигезендә дәүләт ярдәме күрсәтелергә мөмкин:

мәнфәгатьләр уртаклыгы нигезендә берләшкән 30 яшькә кадәрге гражданнарның төбәкара, республика һәм җирле яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә;

уртак эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен берләшкән 18 яшькә кадәрге һәм балигъ булган гражданнарның төбәкара, республика һәм җирле балалар иҗтимагый берләшмәләренә.

Яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренә дәүләт ярдәме түбәндәге шартлар үтәлгән очракта күрсәтелә:

берләшмә юридик зат булып торса һәм дәүләт теркәве үткән вакыттан кимендә бер ел Татарстан Республикасы территориясендә эшләсә;

берләшмә кимендә 50 әгъзадан торса.

Дәүләт ярдәме сорап мөрәҗәгать иткән яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең әлеге Законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенче вәкаләтле органы тарафыннан ачыклана.

Яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең, оештыру ягыннан мөстәкыйльлеген саклаган килеш, яшьләрнең яисә балаларның башка берләшмәләре белән ассоциациягә (берлеккә) берләшүе аны дәүләт ярдәме объектлары исемлегеннән төшереп калдыру өчен нигез була алмый.»;

3) түбәндәге эчтәлекле 11[1] статья өстәргә:

«11[1] статья. **Дәүләт ярдәменнән файдалана торган яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең республика реестры**

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенча вәкаләтле органы Дәүләт ярдәменнән файдалана торган яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең республика реестрын (алга таба – Республика реестры) булдыра һәм алып бара.

Яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрен Республика реестрына кертү яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсе язмача гариза һәм үзенең әлеге Законның 11 статьясындагы өченче өлеше таләпләренә туры килүен раслый торган документларны тапшырганнан соң 30 көн эчендә түләүсез гамәлгә ашырыла.

Республика реестрына кертелгән яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре ике елга бер тапкыр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенча вәкаләтле органына яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең әлеге Законның 11 статьясындагы өченче өлеше таләпләренә туры килүен раслый торган документлар тапшыра.



Республика реестрына яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсе турында түбәндәге белешмәләр кертелә:

тулы һәм (әгәр булса) кыскартылган исеме, даими эшли торган җитәкче органының адресы (урнашкан урыны);

дәүләт теркәве турындагы язуның дәүләт теркәве номеры (төп дәүләт теркәве номеры);

салым түләүченең идентификация номеры;

исәпкә куелу сәбәбе коды;

Россия Федерациясе пенсия фондында теркәү номеры;

әгъзалары саны;

яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсен төзүнең һәм аның эшчәнлегенең устав нигезендәге максаты;

яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсе башкара торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат;

аны Республика реестрына кертү датасы;

аны Республика реестрыннан төшереп калдыру датасы һәм нигезе.

Республика реестрына кертелгән яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсе бу реестрдан түбәндәге нигездә чыгарылырга мөмкин:

яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең язмача гаризасы;

яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең әлеге Законның 11 статьясындагы өченче өлеше таләпләренә туры килмәве ачыкланганда, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенча вәкаләтле органы карары.

Яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсен Республика реестрыннан чыгару турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенча вәкаләтле органы кабул ителгән карар турында мондый берләшмәгә язмача хәбәр итә.

Республика реестрын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенча вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенча вәкаләтле органы дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча федераль башкарма хакимият органына Республика реестрына кертелгән берләшмәләр турында һәр квартал саен әлеге статьяның дүртенче өлешендәге икенче – тугызынчы абзацларында күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра.»;

4) 12 статьяда «махсус» сүзен төшереп калдырырга;

5) 15 статьяның беренче өлешендә «учреждениеләренең» сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 20 гыйнвары
№ 5-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 6. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның алтынчы абзацында «һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы вәкаләтләре**

Җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

файдалы казылмаларның разведкаланган запаслары турындагы һәм җир асты байлыкларының кыйммәтен яисә куркынычлылыгын билгели торган башка үзенчәлекләре турындагы мәгълүматка дәүләт экспертизасында катнашу;

республиканың геологик мәгълүмат фондларын төзү һәм алып бару, Татарстан Республикасы бюджеты һәм тиешле җирле бюджетлар акчалары исәбенә алынган мәгълүмат белән эш итү;

җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органнары белән килештереп, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлекләрен әзерләү һәм раслау;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары һәм яткан урыннары запасларының республика балансларын һәм кадастрларын төзү һәм алып бару, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү өчен файдаланыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләрен исәпкә алу;

файдалы казылмалар запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик, икътисадый һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы ясау;

җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү турындагы гарызнамәләрне карау өчен җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итүнең федераль органы тарафыннан төзелә торган комиссия эшендә катнашу;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын бирү;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануны лицензияләүнең дәүләт системасы эшләвен тәэмин итү;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану шартларын әзерләү;

җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануны лицензияләү программасын төзү, җир асты кишәрлекләреннән файдалану хокукына конкурслар яисә аукционнар үткәрү шартлары һәм җир асты кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләр шартлары турында тәкъдимнәрне җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итүнең федераль органына яисә аның территориаль органнарына тапшыру;

федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына конкурслар һәм аукционнар үткәрүдә җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органнары та-

рафыннан төзелә торган конкурс һәм аукцион комиссияләре составында катнашу;

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын чыгаруның техник проектларын һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләр башкаруга бүтән проект документациясен килештерү;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләү ставкасының төгәл күләмен җир асты байлыкларыннан файдалануга билгеләнгән тәртиптә лицензия бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләренең һәркайсына аерым-аерым федераль законнарда каралган чикләрдә билгеләү;

законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

3) 16 статьяның унынчы абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте» сүзләрен «җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә итү» сүзләренә алмаштырырга;

4) 95 статьяның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар ятмаларының һәм яткан урыннарның дәүләт кадастрын һәм файдалы казылмалар запасларының дәүләт балансын төзү һәм алып бару тәртибен билгеләү;».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның гамәлдә булу көче 2014 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 20 гыйнвары
№ 6-ТРЗ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 7. «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» 2011 елның 22 апрелендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасының 3 бүлегенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.1 бүлекчәнең 3.1.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 19 – 22 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «19. Татарстан Республикасы Геопорталының өзлексез эшләвен, аны актуальләштерүне һәм тулыландыруны тәэмин итәргә | Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, тармак министрлыклары һәм ведомстволары | 2014 – 2015 еллар |
| 20. Иҗтимагый инфраструктура объектларының бердәм (республика һәм муниципаль) электрон белешмәләр базасын булдырырга | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, тармак министрлыклары һәм ведомстволары, җирле үзидарә органнары (килештерү буенча) | 2015 ел |
| 21. Маневрлы торак фонды булдыруны тәэмин итәргә | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциясез оешмасы (килештерү буенча), җирле үзидарә органнары (килештерү буенча) | 2015 ел |

| | | |
|---|---|---|
| 22. Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренең, аларның характеристикаларын тасвирлап, электрон белешмәләр базасын булдырырга һәм аны актуаль хәлдә тотарга | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 2014 – 2015 еллар»; |

2) 3.2 бүлекчәнең 3.2.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 17 – 20 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «17. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә сәнәгать мәйданчыклары челтәрен үстерү концепциясен эшләргә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килештерү буенча) | 2014 – 2015 еллар |
| 18. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яңартуны, аларны яңадан технологик тәэмин итүне кызыксындыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын әзерләргә һәм гамәлгә ашырырга | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, тармак министрлыклары һәм ведомстволары | 2014 – 2015 еллар |
| 19. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә уңайлы инвестиция климатын тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеге стандартын гамәлгә кертүне тәэмин итәргә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килештерү буенча) | 2014 – 2015 еллар |
| 20. Инвестиция проектларын «бер тәрәзә» режимында алып баруны тәэмин итәргә | Татарстан Республикасы Инвестиция үсеше агентлыгы, тармак министрлыклары һәм ведомстволары | 2014 – 2015 еллар»; |

3) 3.3 бүлекчәнең 3.3.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 – 14 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «12. Татарстан Республикасы икътисадының һәм социаль өлкәсенең өстенлекле тармакларына югары квалификацияле белгечләрне җәлеп итү чаралары комплексын әзерләргә | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, тармак министрлыклары һәм ведомстволары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге | 2015 елның 1 кварталы |



| | | |
|---|---|---|
| 13. Сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәсендәге, сәнәгать секторындагы югары квалификацияле белгечләрне аренда торагы белән тәэмин итү тәртибен әзерләргә һәм гамәлгә кертергә | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциясез оешмасы (килештерү буенча) | 2014 елның 2 кварталы |
| 14. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшенең нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрүне оештырырга | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2014 ел»; |

4) 3.4 бүлекчәнең 3.4.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 19, 20 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «19. Югары һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, тармак һәм ведомство фәнни-тикшеренү институтлары тарафыннан үткәрелә торган фәнни тикшеренүләрне интеграцияләү системасын әзерләргә һәм гамәлгә кертергә | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 2015 елның 1 кварталы |
| 20. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе фәнни-тикшеренү институтларының һәм үзәкләренең гамәли тикшеренүләр планнарын һәм аларны үтәү турында хисапларны урнаштырырга | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе (килештерү буенча) | 2014 – 2015 еллар»; |

5) 3.5 бүлекчәнең 3.5.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «10. Татарстан Республикасы Инвестиция порталында республика һәм Россия товар базарларының структурасы һәм товар үткәрә алу мөмкинлеге, инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәт, җитештерү һәм инфраструктура ресурсларының туплануы турында мәгълүмат урнаштырырга һәм аны актуаль хәлдә тотарга | Татарстан Республикасы Инвестиция үсеше агентлыгы, Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты, тармак министрлыклары һәм ведомстволары | 2014 – 2015 еллар»; |

6) 3.6 бүлекчәнең 3.6.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «13. Гражданнарның төзекләндерү һәм инфраструктураны үстерү проектларын гамәлгә ашыруда катнашу механизмын гамәлгә кертү буенча Чистай муниципаль районы тәҗрибәсен барлык муниципаль берәмлекләргә таратырга | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, тармак министрлыклары һәм ведомстволары, җирле үзидарә органнары (килештерү буенча) | 2014 – 2015 еллар»; |

7) 3.8 бүлекчәнең 3.8.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9 – 11 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «9. Татарстан Республикасының норматив хокукый актлар проектларының, норматив хокукый актларының һәм муниципаль норматив хокукый актларның җайга салу йогынтысын бәяләү системасын гамәлгә кертергә | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, тармак министрлыклары һәм ведомстволары, җирле үзидарә органнары (килештерү буенча) | Республика дәрәҗәсендә 2014 елның 1 кварталы, муниципаль дәрәҗәдә 2015 елның 1 кварталы |
| 10. Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү органнарының электрон белешмәләр базасына интеграцияләнгән югары уку йортларын тәмамлаучыларның республика электрон белешмәләр базасын булдырырга | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, югары уку йортлары (килештерү буенча) | 2014 – 2015 еллар |
| 11. Бюджет өлкәсендәге гомуми тармак профессияләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне арттыру буенча чаралар әзерләргә | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, тармак министрлыклары һәм ведомстволары | 2014 елның 2 кварталы»; |

8) 3.9 бүлекчәнең 3.9.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «5. Кече һәм урта эшкуарлык секторында финанс ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын әзерләргә һәм гамәлгә ашырырга | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 2014 –2015 еллар»; |

9) 3.10 бүлекчәнең 3.10.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10 – 12 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «10. Дәүләт граждан хезмәткәрләренә аларның эш нәтиҗәлелегенә бәйле рәвештә хезмәт өчен түләү тәртибен әзерләргә | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы | 2014 ел |
| 11. Татарстан Республикасы Инвестиция порталында дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүләр реестрын урнаштырырга һәм аны актуаль хәлдә тотарга | Татарстан Республикасы Инвестиция үсеше агентлыгы | 2014 – 2015 еллар |
| 12. Дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендәге федераль һәм республика законнары базасын формалаштыруын исәпкә алып, дәүләти-хосусый партнерлык мөнәсәбәтләрендә дәүләти-хосусый партнерлыкның һәм аларда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең катнашуының яңа рәвешләрен үстерергә | Татарстан Республикасы Инвестиция үсеше агентлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килештерү буенча) | 2014 елның 2 кварталы»; |

10) 3.11 бүлекчәнең 3.11.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10, 11 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «10. Татарстан Республикасында торак-коммуналь хуҗалык акчалары керүнең һәм тотылуның торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү турында халыкка SMS-хәбәрләр һәм электрон почта аша хәбәр итү мөмкинлеге булган исәпкә алу системасын электрон рәвештә гамәлгә ашырырга | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасының дәүләт заказы, инвестиция эшчәнлеге һәм регионара бәйләнешләр агентлыгы» дәүләт унитар предприятиесе, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы | 2014 ел |
| 11. Инвестиция программаларының җайга салына торган өлкәләргә йогынтысын исәпкә алу системасын кертүне тәэмин итәргә | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килештерү буенча) | 2014 ел»; |

11) 3.12 бүлекчәнең 3.12.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 18, 19 пунктчалар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «18. Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүнең комплекслы системасын гамәлгә кертергә | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | 2015 елның 1 кварталы |
| 19. Дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә предприятиеләрдә экология идарәсе системаларына ирекле сертификация үткәрүне һәм (яисә) «яшел» стандартлар системасы буенча ирекле экология сертификациясе уздыруны исәпкә алырга | тармак министрлыклары һәм ведомстволары | 2015 елның 1 кварталы». |

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 20 гыйнвары
№ 7-ТРЗ



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 8. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$) хосусыйлаштырылганда электр челтәре хуҗалыклары объектларына, җылылык энергиясе чыганакларына, җылылык челтәрләренә, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларына һәм мондый системаларның аерым объектларына салынган эксплуатация йөкләмәләре шартларының үтәлешен тикшереп тору тәртибен билгели;»;

2) 8 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

дәүләт мөлкәтенең исеме һәм аны индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүматлар (мөлкәткә характеристика);

дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру алымы;

мөлкәтнең башлангыч бәясе;

кичектереп түләү срогы (бирелгән очракта);

дәүләт мөлкәтен бәяләү нәтиҗәләре;

дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өчен кирәкле башка белешмәләр.

Унитар предприятиенең мөлкәт комплексын хосусыйлаштыру очрагында дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда шулай ук түбәндәгеләр дә раслана:

унитар предприятиенең хосусыйлаштырылырга тиешле мөлкәт комплексы составы;

унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиеш булмаган объектлар исемлеге (шул исәптән чыгарылма хокуклар);

унитар предприятиене үзгәртеп кору юлы белән төзелә торган ачык акционер җәмгыятьнең яисә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталы күләме;

ачык акционер җәмгыять акцияләренең саны, категориясе һәм номиналь бәясе яисә Татарстан Республикасы өлешенең номиналь бәясе.

Электр челтәре хуҗалыклары объектларын, җылылык энергиясе чыганакларын, җылылык челтәрләрен, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларын һәм мондый системаларның аерым объектларын хосусыйлаштырган очракта, хосусыйлаштыру турындагы карар составына «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның $30^1$ статьясы нигезендә рәсмиләштерелгән инвестиция һәм эксплуатация шартлары кертелергә тиеш.

Унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиеш булмаган объектлар (шул исәптән чыгарылма хокуклар) башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан алына.

Дәүләт предприятиесе ачык акционер җәмгыять итеп үзгәртелгән очракта, башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы мондый предприятиене хосусыйлаштыру планын төзү турында карар кабул итәргә мөмкин. Хосусыйлаштыру планы рәвеше башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан раслана.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 20 гыйнвары
№ 8-ТРЗ





## 9. Татарстан Республикасында универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләре турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Закон «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген оештыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген оештыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгеләү;

2) универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле оешманы (алга таба – вәкаләтле оешма) билгеләү;

3) дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәт күрсәтүләрдән файдалануга авторлаштырылган мөмкинлекне тәэмин итә торган региональ һәм муниципаль электрон кушымталар исемлеген билгеләү;

4) Татарстан Республикасында универсаль электрон карта дубликатын бирү тәртибен һәм мондый дубликатны биргән өчен түләү күләмен билгеләү;

5) Татарстан Республикасында универсаль электрон карталарны илтеп җиткерү тәртибен билгеләү, шул исәптән шәхсән гражданның үзенә;

6) Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән электрон кушымталар әзерләү, аларны тоташтыру һәм аларның эшләү кагыйдәләрен һәм электрон кушымталарга карата техник таләпләрне билгеләү;

7) универсаль электрон карта кулланып, дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының мәгълүмати-технологик үзара эшчәнлеген оештыру, шул исәптән универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча вәкаләтле оешманың эше өчен мәгълүматны ачу (мәгълүматтан файдалануга рөхсәт бирүне тәэмин итү) вазыйфалары;

8) Татарстан Республикасын мәгълүматлаштыру программасы кысаларында универсаль электрон карталарны чыгаруны, бирүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тәэмин итү эшчәнлеген финанслауны билгеләү;

9) федераль законнар белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне башкару.

4 статья. **Вәкаләтле орган вәкаләтләре**

1. Универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген оештыруны вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.

2. Вәкаләтле орган:

1) түбәндәгеләрнең тәртибен билгели:

а) Татарстан Республикасында универсаль электрон карта бирү турында гариза бирүнең;

б) Татарстан Республикасында универсаль электрон картаны алмаштыруның;

в) Татарстан Республикасында универсаль электрон картаны алудан баш тартуның;

г) гражданның электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүче банкны сайлау турында мәгълүмат җибәрүенең;

2) әлеге Законның 5 статьясында каралган тәртиптә электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүче банкларны сайлап алу буенча конкурс уздыра;



3) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген оештыруга бәйле башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

5 статья. **Электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүче банкны сайлап алу буенча конкурс уздыру тәртибе**

1. Электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүче банкны сайлап алу буенча конкурс (алга таба – конкурс), электрон банк кушымтасының эшләвен тәэмин итү максатларында, граждан вәкаләтле орган билгеләгән срокта универсаль электрон карта алудан баш тарту турындагы гариза белән вәкаләтле оешмага мөрәҗәгать итмәгән һәм (яисә) вәкаләтле орган билгеләгән срокта электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүче банкны сайлау турындагы мәгълүматны вәкаләтле оешмага җибәрмәгән очракларда уздырыла.

2. Конкурста катнашуга федераль вәкаләтле оешма белән шартнамә төзегән һәм конкурста катнашуга заявка (алга таба – заявка) биргән банклар кертелә.

3. Вәкаләтле орган конкурсны оештыручы була, ул түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсны уздыру датасын билгели;

2) конкурс уздыру турында хәбәрнамәне һәм конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүматны вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра;

3) конкурста катнашучылардан кергән заявкаларны кабул итүне, исәпкә алуны һәм саклауны тәэмин итә;

4) конкурста катнашучыларга аның нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

4. Вәкаләтле орган конкурсны уздыру өчен конкурс комиссиясе төзи. Конкурс комиссиясе әгъзаларының саны җиде кешедән ким була алмый. Конкурс комиссиясе утырышта әгъзаларының кимендә яртысы катнашканда карарлар кабул итәргә хокуклы, бу чакта конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Конкурс комиссиясе карарлары аның утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары тавышлары саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып санала. Конкурс комиссиясе карарлары беркетмәләр рәвешендә

рәсмиләштерелә, аларга конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары имза сала. Конкурс комиссиясе үз эшенә бәйсез экспертларны җәлеп итәргә хокуклы.

5. Түбәндәге физик зат конкурс комиссиясе әгъзасы, бәйсез эксперт була алмый:

1) заявкалар биргән банклар белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы;

2) электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәтләр күрсәтүләргә дәгъва кылучы банкларга карата йогынтылы зат булучы;

3) заявкалар биргән банкларның катнашучысы (акционеры), аларның идарә органнарының әгъзасы яисә банкларның кредиторы булучы;

4) суд карары белән хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган.

6. Конкурс комиссиясе составында әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән затлар ачыкланган очракта, вәкаләтле орган бер эш көне эчендә аларны конкурс нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынмый торган башка физик затларга алмаштырырга тиеш.

7. Конкурс комиссиясе түбәндәге функцияләрне башкара:

1) тәкъдим ителгән документлардагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерә, шулай ук сайлап алу критерийлары буенча заявкаларны бәяли;

2) заявкалары булган конвертларны ача;

3) тәкъдим ителгән заявкалардагы белешмәләрнең дөреслеген раслау максатларында дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан алар карамагындагы кирәкле мәгълүматны соратып ала;

4) конкурс нәтиҗәләре турында карар кабул итә.

8. Конкурс уздыру турындагы хәбәрнамә заявкалар кабул итүнең тәмамлану көненә кадәр кимендә 30 календарь көннән ким булмаган вакытта вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

9. Конкурс уздыру турындагы хәбәрнамәдә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) конкурс предметы;

2) заявкалары булган конвертларны ачу датасы, вакыты һәм урыны;

3) заявкаларны кабул итүнең башлану һәм тәмамлану датасы;



4) заявкаларны тапшыру вакыты һәм урыны;

5) заявкаларны кабул итүче затның контакт телефоны номеры;

6) сайлап алу критерийлары;

7) заявкадагы документлар исемлеге.

10. Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында заявканың вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган формасы урнаштырыла.

11. Заявка составында түбәндәге документларның булуы мәҗбүри таләп булып тора:

1) вәкаләтле орган раслый торган форма буенча хатның;

2) универсаль электрон картаның электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәт күрсәтүләрне күздә тота торган федераль вәкаләтле оешма белән шартнамәнең нотариаль таныкланган күчермәсенең;

3) гамәлгә кую документлары күчермәләренең;

4) җитәкче (вәкаләтле зат) тарафыннан һәм конкурста катнашучы мөһере белән таныкланган һәм конкурста катнашучының Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр системасын үстерүгә җибәреләчәк финанс чаралары күләмен чагылдыра торган документларның;

5) конкурста катнашучының милек хокукындагы Татарстан Республикасы территориясендәге программа-техник чараларының (банкоматларының, түләү терминалларының) санын раслый торган документларның йә программа-техник чаралардан файдалану турында башка банклар белән төзелгән һәм конкурста катнашуга заявка бирү вакытына кадәр кимендә бер ел гамәлдә булган килешүләрнең.

12. Банк үз ихтыяры буенча түбәндәге документларны тәкъдим итәргә хокуклы:

1) юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсен;

2) вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында конкурс уздыру турында хәбәрнамә урнаштыру көненә кадәр кимендә алты айдан да иртәрәк булмаган вакытта алынган Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәсен яисә аның нотариаль таныкланган күчермәсен.

13. Банк әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, вәкаләтле орган күрсәтелгән документларны ведомствоара мәгълүмати үзара эшчәнлек тәртибендә соратып ала.

14. Заявка язма рәвештә кәгазь чыганакта, ябыштырылган конвертта тапшырыла. Конвертта конкурс исеме күрсәтелә. Заявканың барлык битләре тегелгән һәм аларга номер куелган булырга тиеш. Заявкада аның составына керә торган документларның исемлеге булырга тиеш, заявка банк мөһере һәм вәкаләтле зат имзасы белән расланырга тиеш.

15. Банк конкурста катнашуга бәйле барлык чыгымнарны мөстәкыйль рәвештә үзе түли. Вәкаләтле орган, конкурс уздыру характерына һәм аның нәтиҗәләренә бәйсез рәвештә, әлеге чыгымнар буенча җавап бирми, һәм алар буенча аның йөкләмәләре дә булмый.

16. Һәр банк конкурста катнашу өчен бер генә заявка бирергә мөмкин.

17. Банк түбәндәгеләргә хокуклы:

1) конвертта үзенең фирма атамасын һәм почта адресын күрсәтмәскә;

2) заявкалары булган конвертларны конкурс комиссиясе ачкан вакытка кадәр теләсә кайсы вакытта заявкасын үзгәртергә яисә чакыртып алырга.

18. Конкурс документларында күрсәтелгән срокта килгән конкурста катнашуга заявкасы булган һәр конверт вәкаләтле орган тарафыннан аның кергән көнендә теркәлә. Вәкаләтле орган заявкасы булган конверт биргән банкның таләбе буенча заявкасы булган конвертны алуына, аны алу датасын һәм вакытын күрсәтеп, расписка бирә.

19. Конкурс комиссиясе әгъзаларына конкурс комиссиясе утырышын уздыру урыны, датасы һәм вакыты турында үз вакытында хәбәр ителергә тиеш. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан читтән торып тавыш бирүне үткәрү юлы белән карарлар кабул итү, шулай ук аларның үз вәкаләтләрен башка затларга тапшыру рөхсәт ителми.

20. Заявкалары булган конвертларны ачу заявкалар бирү тәмамланган көннән алып өч эш көне эчендә конкурс комиссиясе тарафыннан аның утырышында башкарыла. Конкурста катнашуга заявка биргән банкларның вәкаләтле вәкилләре заявкалары булган конвертларны ачуда катнашырга хокуклы.

21. Конвертларны ачканда банкның исеме һәм почта адресы, тапшырылган белешмәләр һәм документлар игълан ителә. Барлык мәгълүмат конкурс комиссиясе тарафыннан конвертларны ачу беркетмәсенә кертелә, һәм аларны ачу тәмамланганнан соң ук конкурс комиссиясендә катнашучы барлык әгъзалар тарафыннан беркетмәгә имза салына.



22. Конвертларны ачу беркетмәсе аңа имза салынган көнне вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

23. Конкурс комиссиясе заявкалары булган конвертларны ачкан көннән алып 10 календарь көн эчендә заявкаларны әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килү-килмәү предметына, шулай ук тәкъдим ителгән документларда дөрес булмаган (чынбарлыкка туры килмәгән) һәм (яисә) тулы булмаган белешмәләр булуны карый.

24. Конкурс комиссиясе заявкалары булган конвертларны ачкан көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча заявкаларны карау нәтиҗәләре нигезендә конкурста катнашуга кертү турында йә конкурста катнаштыруны кире кагу хакында карар кабул итә.

25. Әлеге статьяның 24 өлешендә күрсәтелгән карар конкурс комиссиясе утырышын уздырган көнне конкурс заявкаларын карау беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә. Конкурс заявкаларын карау беркетмәсенә конкурс комиссиясендә катнашучы барлык әгъзалар тарафыннан имза салына. Кабул ителгән карар турында конкурс комиссиясе карарын кабул иткән көннән алып өч эш көне эчендә заявкалар биргән бөтен банкларга хәбәр ителә.

26. Конкурс заявкаларын карау беркетмәсендә конкурс заявкалары биргән банклар турында белешмәләр, аларны конкурста катнашуга кертү һәм аларны конкурста катнашучылар итеп тану хакында йә, сәбәпләрен күрсәтеп, конкурста катнаштыруны кире кагу турында карар булырга тиеш.

27. Конкурс заявкаларын карау беркетмәсе аңа имза салынган көнне вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

28. Конкурста катнаштыруны кире кагуның нигезләре түбәндәгеләр:

1) банкларның әлеге статьяның 11 өлешендә билгеләнгән документларны тапшырмавы;

2) тәкъдим ителгән документларда дөрес булмаган һәм (яисә) тулы булмаган белешмәләр булу.

29. Конкурс комиссиясе конкурс заявкаларын карау беркетмәсенә имза салынган көннән алып өч эш көне эчендә конкурста катнашуга кертелгән һәм конкурста катнашучылар итеп танылган банкларның (алга таба – катнашучы банклар) конкурс заявкаларын бәяли.

30. Конкурс заявкаларын бәяләү түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:

1) катнашучы банкның милек хокукындагы йә башка банклар белән төзелгән һәм конкурста катнашуга заявка бирү вакытына кадәр кимендә бер ел гамәлдә булган килешүләр нигезендә катнашучы банк тарафыннан файдаланыла торган программа-техник чараларының (банкоматларның, түләү терминалларының) Татарстан Республикасы территориясендәге саны;

2) катнашучы банкның Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр системасын үстерүгә җибәреләчәк финанс чаралары күләме.

31. Катнашучы банкны конкурста җиңүче итеп тану турында конкурс комиссиясе карары конкурста катнашуга кертелгән һәм конкурста катнашучылар итеп танылган банкларның конкурс заявкаларын бәяләү тәмамланган көннән алып өч календарь көн эчендә кабул ителә һәм конкурс заявкаларын бәяләү беркетмәсенә кертелә.

32. Конкурс заявкаларын бәяләү беркетмәсендә катнашучы банкларның конкурс заявкаларын бәяләү тәртибе әлеге статьяның 30 өлешендә билгеләнгән сайлап алу критерийлары нигезендә күрсәтелергә тиеш.

33. Конкурс заявкаларын бәяләү беркетмәсенә конкурс заявкаларын бәяләгәннән соң ук конкурс комиссиясендә катнашучы барлык әгъзалар тарафыннан имза салына.

34. Конкурс заявкаларын бәяләү беркетмәсе аңа имза салынган көнне вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

35. Вәкаләтле орган конкурс заявкаларын бәяләү беркетмәсенә имза салынган көннән алып өч календарь көннән дә соңга калмыйча катнашучы банкларга конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрнамәләр җибәрә.

36. Катнашучы банкны конкурста җиңүче итеп тану турында конкурс комиссиясе карары нигезендә вәкаләтле оешма конкурс заявкаларын бәяләү беркетмәсе вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган көннән алып 10 календарь көннән дә иртәрәк булмаган һәм 20 календарь көннән дә соңрак булмаган вакытта универсаль электрон картаның электрон банк кушымтасы кысаларында конкурста җиңүче белән хезмәт күрсәтүләргә шартнамә төзи.

37. Конкурста җиңүче универсаль электрон картаның электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәт күрсәтүләргә



шартнамә төзүдән баш тарткан очракта, вәкаләтле оешма конкурс заявкаларын бәяләү нәтиҗәләре буенча икенче тәртип саны бирелгән катнашучы банк белән шундый шартнамә төзи.

38. Конкурс комиссиясе түбәндәге очракларда конкурсны узмаган дип тану турында карар кабул итә:

1) әгәр бер генә банк та конкурс заявкасы бирмәсә, – заявкалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә;

2) әгәр заявкалар биргән барлык банкларны конкурста катнаштыру кире кагылса, – заявкалар биргән банкларны конкурста катнаштыруны кире кагу турында карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә;

3) әгәр конкурста җиңүче, шулай ук конкурс заявкаларын бәяләү нәтиҗәләре буенча икенче тәртип саны бирелгән катнашучы банк универсаль электрон картаның электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәт күрсәтүләргә шартнамә төзүдән баш тартса, – конкурста җиңүче яисә конкурс заявкаларын бәяләү нәтиҗәләре буенча икенче тәртип саны бирелгән катнашучы банк универсаль электрон картаның электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәт күрсәтүләргә шартнамә төзүдән баш тартканнан соң бер эш көне эчендә.

39. Конкурс узмаган дип танылган очракта, вәкаләтле орган конкурс комиссиясе конкурсны узмаган дип тану турында карар кабул иткән көннән алып 10 эш көне эчендә кабат конкурс уздыру турында карар кабул итә.

### 6 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 20 гыйнвары
№ 9-ТРЗ

## 10. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пункты өченче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 13 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пункты өченче абзацының гамәлдә булуын 2015 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш).

**2 статья**

2014 елда Татарстан Республикасы дәүләт программалары 2014 елның 1 маена кадәр «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 94-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерелергә тиеш.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 21 феврале
№ 10-ТРЗ





## 11. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 13 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.14 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «һәм спорт» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 өлешнең беренче абзацында «, спорт» сүзен төшереп калдырырга;

3) 3 өлешнең беренче абзацында «һәм спорт» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 28 феврале
№ 11-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 12. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 13 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктына «, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары» сүзләрен өстәргә;

2) 17 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Халыкка хокукый мәгълүмат җиткерү һәм аны хокукый гыйлемле итү югары белем бирү мәгариф оешмаларының юридик клиникалары һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 28 феврале
№ 12-ТРЗ



# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 13. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның язгы сессиясе секретариаты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның язгы сессиясе секретариатын түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Секретариат җитәкчесе:
Захматова Анна Андреевна

Секретариат әгъзалары:
Әхмәтҗанов Ислам Галиәхмәт улы
Исаева Анастасия Георгиевна
Рачков Сергей Геннадьевич
Сәйфетдинов Антон Ренат улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3315-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 14. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның язгы сессиясе регламент төркеме турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның язгы сессиясе регламент төркемен

түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Төркем җитәкчесе:
Газизов Генар Җанбәк улы

Төркем әгъзалары:
Табакчи Гөлнара Альберт кызы
Сәлахов Мәгъсүм Хәлимулла улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3316-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 15. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның язгы сессиясе электрон системадан файдаланып тавыш бирүне тикшереп тору комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның язгы сессиясе электрон системадан файдаланып тавыш бирүне тикшереп тору комиссиясен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Комиссия җитәкчесе:
Малыхина Лариса Витальевна

Комиссия әгъзалары:
Абдуллин Камил Фәргать улы
Григорьев Андрей Парамонович.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3317-IV ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 16. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның язгы сессиясе редакция комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның язгы сессиясе редакция комиссиясен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Редакция комиссиясе җитәкчесе:
Шәфигуллин Лотфулла Нурислам улы

Редакция комиссиясе әгъзалары:
Еремеева Гүзәл Вилсур кызы
Прокофьев Артем Вячеславович
Самаренкин Дмитрий Анатольевич
Хәйруллин Илшат Нәҗип улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3318-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 17. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык сигезенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы Лаеш суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

2. Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

3. «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 519-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

4. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 529-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

5. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 540-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

6. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 549-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

7. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 559-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

8. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 568-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 569-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 560-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 562-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 563-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 573-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).



14. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 550-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пункты өченче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 578-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 570-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның $16^6$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 572-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 567-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 577-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

20. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 564-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

21. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында.

22. «Татарстан Республикасы Әтнә районы территориясендә торак пункт – Яңа Әтнә авылын төзү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

23. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.

24. «Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертү хакында.

25. «Татарстан Республикасы законнары җыелмасын бастырып чыгару буенча республика комиссиясен төзү турында»

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

26. Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында доклад.

27. Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының 2013 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында хисабы.

28. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 390485-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүче чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга карата Россия Федерациясенең аларга вакытлыча яшәү рөхсәт ителгән субъектында гына яшәү мөмкинлеге буенча билгеләнгән чикләүне бетерү турында).

29. «Азартлы уеннарны законсыз оештырган һәм уздырган өчен җаваплылыкны көчәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 318436-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.31 һәм 8.32 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 391503-6 номерлы федераль закон проекты турында (урманнарда санитария һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү турында).

31. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 393165-6 номерлы федераль закон проекты турында (автобусларда пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салу өлешендә).

32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясына балигъ булмаганнарның ата-аналары яисә башка законлы вәкилләренең балигъ булмаганнарны карап тоту, тәрбияләү, укыту, аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәреш кертү хакында» 398424-6 номерлы федераль закон проекты турында.

33. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 421419-6 номерлы федераль закон проекты турында (донор каны белән эш йөртү өлкәсендә законнарны бозган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында).



34. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында.

35. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасы турында.

36. «Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» Федераль законның 15 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Магадан өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

37. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 415556-6 номерлы федераль закон проекты турында.

38. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $14^1$, $15^1$ һәм $16^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 421486-6 номерлы федераль закон проекты турында.

39. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 150 статьясына үзгәреш кертү турында» 415703-6 номерлы федераль закон проекты хакында (фәнни тикшеренүләр өчен кертелә торган чыгым материалларын өстәлгән бәягә салымга салым салынудан азат итү өлешендә).

40. «Почта элемтәсе турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү хакында» 418752-6 номерлы федераль закон проекты турында.

41. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 һәм $179^4$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

42. «Ветераннар турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү турында» 401840-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе сәламәтлек саклап калу

системасында сугыш ветераннары өчен госпитальләр структурасын саклауның өстәмә гарантияләре турында).

43. «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 418883-6 номерлы федераль закон проекты турында (ата-анасы билгеле булмаган балаларга туендыручысын югалткан очракта социаль пенсиягә хокук бирү хакында).

44. «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 420241-6 номерлы федераль закон проекты турында (ата-анасы билгеле булмаган балаларга туендыручысын югалткан очракта социаль пенсиягә хокук бирү хакында).

45. «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмуртия Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

46. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына дәүләт җир күзәтчелеген камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 421545-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

47. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль законның 19[1] статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Рязань өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

48. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 12 һәм 20 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Саха (Якутия) Республикасы Дәүләт Собраниесенең (Ил Тумэн) закон чыгару инициативасы турында.

49. «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 415028-6 номерлы федераль закон проекты хакында (этил спиртын һәм алкоголь продукциясен оешманың бер аерым бүлекчәсе тарафыннан җитештерүне тыюны төгәлләштерү өлешендә).

50. «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 421531-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт кадастр бәяләвен камилләштерү өлешендә).



51. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 400896-6 номерлы федераль закон проекты турында (көнкүреш билгеләнешендәге пиротехника әйберләренә янгын куркынычсызлыгы буенча өстәмә таләпләр билгеләү өлешендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен төгәлләштерү турында).

52. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 419909-6 номерлы федераль закон проекты турында (Кодексның 20.1, 20.20 һәм 20.21 статьяларында каралган хокук бозуларны кылган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү турында).

53. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 419182-6 номерлы федераль закон проекты турында (балигъ булмаганнарга алкоголь продукциясен ваклап саткан өчен юридик затларга административ җаваплылыкны көчәйтү хакында).

54. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 420986-6 номерлы федераль закон проекты турында (Кодексның 14 бүлегенә административ хокук бозуларның яңа составларын өстәү хакында).

55. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 418857-6 номерлы федераль закон проекты турында (һава судноларын эксплуатацияләүдә иминлек кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

56. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына миграция өлкәсендәге законнарны бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 419207-6 номерлы федераль закон проекты турында (чакырылган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат Россия Федерациясендә булган чорда, аларга карата чакырган як тарафыннан матди, медицина һәм торак ягыннан тәэмин итү чаралары күрелмәгән өчен административ җаваплылыкка тартыла торган субъектлар исемлегенә физик затларны кертү турында, шулай ук Россия Федерациясе миграция законнарын төрлечә бозган өчен салына торган административ штрафлар күләмнәрен арттыру хакында).

57. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 26.7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 403676-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозу турындагы эш буенча дәлил итеп таныла торган документларның эчтәлеген төгәлләштерү өлешендә).

58. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 395531-6 номерлы федераль закон проекты турында (хайваннарга карата кырыс мөнәсәбәтне пропагандалаган өчен административ җаваплылык билгеләү турында).

59. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясындагы 2 өлешенә һәм 28.7 статьясындагы 1 өлешенә үзгәрешләр кертү хакында» 421518-6 номерлы федераль закон проекты турында (Кодексның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү өлешендә).

60. «Шәхси белешмәләр турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 416052-6 номерлы федераль закон проекты турында (оператор кушуы буенча шәхси белешмәләрне эшкәртү тәртибен төгәлләштерү, шулай ук эшкәртелә торган шәхси белешмәләрнең иминлеген тәэмин итү таләпләрен төгәлләштерү өлешендә).

61. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 428889-6 номерлы федераль закон проекты хакында (террорчылыкка каршы көрәшне камилләштерү өлешендә).

62. «Оператив-эзләү эшчәнлеге турында» Федераль законның 8 һәм 15 статьяларына һәм «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 306542-6 номерлы федераль закон проекты турында (ачык оператив-эзләү чараларын башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын саклауда прокурор күзәтчелегенең нәтиҗәлелеген арттыру өлешендә).

63. «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 421465-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

64. «Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 415620-6 номерлы федераль закон проекты турында (эчке эшләр органнарының һәлак (вафат) булган гаилә әгъзаларына ай саен акчалата компенсация билгеләү хакында).



65. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

66. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның $12^5$ статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

67. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

68. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының $53^1$ статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы хакында.

69. «Россия Федерациясе гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 399590-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия балаларын әлеге балаларга туган булмаган чит ил гражданнарының уллыкка алуын тыю өлешендә).

70. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 357 статьясына үзгәреш кертү турында» 403431-6 номерлы федераль закон проекты хакында (дәүләт хезмәт инспекторларына судка мөрәҗәгать итү хокукы бирү өлешендә).

71. «Россия Федерациясендә аш тозын йодлаштыру турында» 410102-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

72. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3319-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 18. Татарстан Республикасы Лаеш суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының 7[1] статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Лаеш суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Сәхибгәрәев Рәшит Тәлгать улына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3320-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 19. Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының 7[1] статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Мөксинова Наилә Илдус кызына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3321-IV ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 20. «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы законы хакында (519-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы законын (519-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3322-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 21. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (529-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (529-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3323-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 22. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 540-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 540-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3324-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 23. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 549-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 549-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3325-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 24. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы хакында (549-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (549-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3326-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 25. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 559-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 559-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3327-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 26. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы законы хакында (559-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы законын (559-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3328-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 27. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 568-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты В.Н. Липужина тарафыннан кертелгән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 568-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2014 елның 13 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына кертелә дип билгеләргә.



3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2014 елның 13 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3329-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 28. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 569-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары В.Н. Липужина һәм Н.Н. Рыбушкин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 569-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2014 елның 13 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2014 елның 13 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3330-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 29. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 560-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Прокуроры тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 560-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2014 елның 13 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2014 елның 13 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3331-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 30. «Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 562-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 562-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2014 елның 13 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2014 елның 13 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3332-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 31. «Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 563-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 563-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2014 елның 13 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2014 елның 13 апреленә кадәр эшләп

бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3333-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 32. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 573-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ш.Ш. Яһудин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 573-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3334-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 33. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (573-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»



Татарстан Республикасы законын (573-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3335-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 34. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 550-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.Ә. Гаделшин тарафыннан кертелгән «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 550-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2014 елның 13 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2014 елның 13 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3336-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**35. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пункты өченче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 578-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Ф. Шәрипова тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пункты өченче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 578-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3337-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**36. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пункты өченче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» Татарстан Республикасы законы хакында (578-4 номерлы проект)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пункты өченче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» Татарстан Республикасы законын кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3338-IV ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**37. «Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 570-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 570-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2014 елның 23 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3339-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**38. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның $16^6$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 572-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның $16^6$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 572-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3340-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 39. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның $16^6$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (572-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның $16^6$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (572-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3341-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 40. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 567-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 567-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3342-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 41. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (567-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (567-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3343-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 42. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 577-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 577-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2014 елның 13 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2014 елның 13 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3344-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 43. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 564-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 564-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2014 елның 13 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетына кертелә дип билгеләргә.



3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2014 елның 13 апреленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3345-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 44. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 25 пункты һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 26 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын һәм әлеге схеманың график тасвирламасын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3346-IV ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2014 елның 13 февралендәге
3346-IV ДС номерлы карарына
кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫН САЙЛАУЛАРНЫ ҮТКӘРҮ ӨЧЕН БЕРМАНДАТЛЫ САЙЛАУ ОКРУГЛАРЫ СХЕМАСЫ

## 1 нче Айдаров сайлау округы

Сайлаучылар саны – 54661
Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Волгоград урамы, 32 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Мәскәү районнары территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Мәскәү – Түбән Новгород – Казан – Уфа (М-7 «Волга») федераль трассасы Центральная урамы белән кисешкән ноктадан алып көнбатыш юнәлештә Мәскәү – Түбән Новгород – Казан – Уфа (М-7 «Волга») федераль трассасы буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Зеленодольск муниципаль районы чиге белән чиктәш чигенә кадәр. Алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буенча Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Совет районнары территорияләренең Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чигендәге тоташу ноктасына кадәр. Алга таба Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Совет районнарының чиктәш чиге буйлап Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына кадәр, алга таба Мәскәү – Екатеринбург тимер юлы буйлап «С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе» ААҖгә кадәр, «С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе» ААҖ территориясе чиге буйлап, «С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе» ААҖ территориясен кертмичә, Камчатка урамына кадәр, алга таба Камчатка урамының так ягы буйлап Пржевальский урамына кадәр, Пржевальский урамының так ягы буйлап Ленинград урамына кадәр, Ленинград урамының так ягы буйлап Симонов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Симонов урамының җөп ягы буйлап Норлат урамы белән кисешкәнгә кадәр, Норлат урамы буенча Максимов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба



Максимов урамы буенча Челюскин урамы белән кисешкәнгә кадәр, Челюскин урамының так ягы буйлап Побежимов урамына кадәр, алга таба Побежимов урамының җөп ягы буйлап Караганда урамына кадәр, Караганда урамы буйлап, Побежимов урамы буенча 57а йортын кертмичә, шул йортка кадәр. Алга таба Побежимов урамы буенча 55а, 53 нче йортлар буйлап, аларны кертмичә, Челюскин урамы белән кисешкәнгә кадәр. Алга таба Казан шәһәренең «12 нче номерлы шәһәр клиник больницасы» ААҖ территориясе чиге буйлап, «12 нче номерлы шәһәр клиник больницасы» ААҖне кертеп, Челюскин урамының так ягы буйлап Тэц урамына кадәр, Тэц урамының так ягы буйлап Копылов урамына кадәр, Копылов урамының так ягы буйлап Казан шәһәре Авиатөзелеш районы чигендәге юлүткәргечкә кадәр, алга таба Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Мәскәү районнарының чиктәш чиге буйлап Гудованцев һәм Тэц урамнары кисешкәнгә кадәр, алга таба көнбатыш юнәлештә Казан шәһәре Мәскәү һәм Киров районнарының чиктәш чиге белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре Мәскәү һәм Киров районнарының чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буйлап Мәскәү – Түбән Новгород – Казан – Уфа (М-7 «Волга») федераль трассасы Центральная урамы белән кисешкән ноктага кадәр.

## 2 нче Копылов сайлау округы

Сайлаучылар саны – 53248
Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Волгоград урамы, 32 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Ленинград урамының Пржевальский урамы белән киселешеннән алып Пржевальский урамының җөп ягы буйлап Камчатка урамына кадәр, Камчатка урамының җөп ягы буйлап «С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе» ААҖгә кадәр, алга таба «С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе» ААҖ территориясе чиге буйлап, «С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе» ААҖне кертеп, Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына кадәр, алга таба Казан шәһәренең Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнарының чиктәш чиге буй-

лап Короленко урамына кадәр, алга таба Короленко урамының так ягы буйлап 113 нче йортка кадәр, Короленко урамы буенча 111 нче, 109 нчы йортларны, Октябрь урамы буенча 38, 36, 28, 30 нчы йортларны кертеп, Октябрь урамының так ягы буйлап Гагарин урамы белән кисешкәнгә кадәр, Гагарин урамының җөп ягы буйлап Ибраһимов проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ибраһимов проспектының так ягы буйлап Казан шәһәре Авиатөзелеш районы чигендәге юлүткәргечкә кадәр, алга таба юлүткәргечтән алып Копылов урамының җөп ягы буйлап Тэц урамына кадәр, алга таба Тэц урамының җөп ягы буйлап Челюскин урамына кадәр, Челюскин урамының җөп ягы буйлап, Казан шәһәренең «12 нче номерлы шәһәр клиник больницасы» ААҖ территориясен кертмичә, Побежимов урамы буенча 53, 55, 55а, 57, 57а йортларын кертеп, Побежимов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Челюскин урамының җөп ягы буйлап Максимов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Максимов урамының җөп ягы буйлап Норлат урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Норлат урамы буенча Симонов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Симонов урамының так ягы буенча Ленинград урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ленинград урамының җөп ягы буенча Пржевальский урамы белән кисешкәнгә кадәр.

**3 нче Кремль сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 60000

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Ипподром урамы, 18 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Вахитов районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Кремль дамбасыннан алып Казансу елгасы яры буйлап Казан шәһәре Вахитов районы чиге буенча Казан шәһәре Совет районы белән чигенә кадәр, алга таба Казан шәһәренең Вахитов һәм Совет районнарының чиктәш чиге буйлап тимер юл линиясе белән кисешкәнгә кадәр, алга таба тимер юл линиясе буенча Әбҗәлилов, Тимер юл урамнары буйлап Агрономия урамы белән кисешкәнгә кадәр, Агрономия урамының так ягы буйлап Эсперанто урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Эсперанто урамының җөп ягы буйлап Кабан күле ярына кадәр, алга таба Кабан күле аша күпер буенча Вахитов мәйданына кадәр, Вахитов мәйданыннан алып Габдулла Тукай урамының так ягы буйлап Сара Садыйкова урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Сара



Садыйкова урамының так ягы буйлап Әхтәмов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Әхтәмов урамының җөп ягы буйлап, Кәрим Тинчурин бакчасы территориясен кертеп, Кәрим Тинчурин бакчасы территориясенең көньяк чигенә кадәр, алга таба Кәрим Тинчурин бакчасы һәм «Электрон» стадионы территорияләре арасыннан тимер юл линиясенә кадәр, алга таба тимер юл линиясе буенча Казан шәһәре Вахитов районы чиге буйлап, Яңа Татар зираты территориясен кертмичә, Яңа Татар зиратының төньяк чигенә кадәр, Идел елгасы ярына кадәр, алга таба Идел елгасы яры буйлап елга портының йөк причалы очына кадәр. Алга таба шулай ук Идел елгасы яры буйлап, елга порты, тимер юл вокзалы территорияләрен кертеп, Киров дамбасы белән кисешкәнгә кадәр һәм алга таба Казансу елгасы яры буйлап Кремль дамбасы белән кисешкәнгә кадәр.

**4 нче Яр буе сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 61040

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Восстание урамы, 82 нче йорт

Сайлау округына Югары Ослан районы территориясе һәм Казан шәһәре Киров районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Югары Ослан муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урыннан алып төньяк юнәлештә Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары территорияләренең тоташу ноктасына кадәр, алга таба Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнарының чиктәш чиге буйлап, «Аккош күле» шәһәр урман паркы һәм «Республика клиник инфекция больницасы» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе территорияләрен кертеп, Восстание урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Восстание урамының җөп ягы буйлап Фрунзе урамы белән кисешкәнгә кадәр, Фрунзе урамының җөп ягы буйлап Коләхмәтов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба, Фрунзе һәм Болотников урамнарын кисеп үтеп, Болотников урамы буенча 13а йортына кадәр, Болотников урамы буенча 13а, 17а йортларын кертеп, Репин һәм Солнечная урамнары белән кисешкәнгә кадәр, Солнечная урамы буйлап, Серпухов урамы буенча торак йортларны кертеп, Серпухов урамына кадәр, алга таба «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль

казна предприятиесе территориясе чиге буйлап, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе территориясен кертеп, Казансу елгасының иске үзәненә кадәр, алга таба Казансу елгасының иске үзәне буенча Несмелов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Несмелов урамы буенча Киров дамбасына кадәр, алга таба Киров дамбасы буйлап Казан шәһәре Вахитов районы белән чигенә кадәр, Казан шәһәре Киров һәм Вахитов районнарының чиктәш чиге буйлап һәм Идел елгасы акваториясе буйлап Югары Ослан муниципаль районы белән чигенә кадәр, алга таба, Югары Ослан муниципаль районы территориясен кертеп, Югары Ослан муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урынга кадәр.

**5 нче Зареченский сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 62335

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Восстание урамы, 82 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: «Республика клиник инфекция больницасы» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе территориясеннән алып Казан шәһәре Мәскәү һәм Киров районнарының чиктәш чиге буйлап, «Химград» технополисының сәнәгать территориясен кертеп, Васильченко урамына кадәр, алга таба Васильченко урамының так ягы буйлап, Восстание урамын Коләхмәтов урамына кадәр кисеп үтеп, Коләхмәтов урамының так ягы буйлап Серов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Серов урамының җөп ягы буйлап Лена урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Лена урамының так ягы буйлап Декабристлар урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Декабристлар урамының так ягы буйлап Чистай урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Чистай урамының җөп ягы буйлап Бондаренко урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Бондаренко урамы буйлап, Бондаренко урамы буенча 6 нчы йортны, Солдат урамы буенча 8 нче йортны, «Татмедиа» ААҖ филиалының «Идел-Пресс» полиграфия-бастыру комплексы» территориясен кертеп, Сибгат Хәким урамына кадәр, алга таба Казан шәһәре Мәскәү һәм Яңа Савин районнарының чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре Вахитов районы чиге белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре Вахитов һәм Киров районнарының чиктәш



чиге буйлап Киров дамбасына кадәр, Киров дамбасы буйлап Несмелов урамына кадәр, Несмелов урамы буйлап Казансу елгасының иске үзәненә кадәр, Казансу елгасының иске үзәне буйлап «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе территориясенең көнчыгыш чиге буенча, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе территориясен кертмичә, Солнечная урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Солнечная урамы буйлап, Солнечная урамы буенча йортларны кертеп, Репин урамы белән кисешкәнгә кадәр, Репин урамы буенча торак йортларны, Лазарев урамы буенча 2 нче йортны кертеп, Болотников урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба, Болотников һәм Фрунзе урамнарын кисеп үтеп, Фрунзе һәм Коләхмәтов урамнары кисешкәнгә кадәр, алга таба Фрунзе урамының так ягы буйлап Восстание урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Восстание урамы буйлап «Республика клиник инфекция больницасы» дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе территориясенә кадәр.

**6 нчы Декабристлар сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 60812

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Восстание урамы, 82 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Мәскәү районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Тэц һәм Хлебозавод урамнары киселешеннән алып, Хлебозавод урамы буенча торак йортларны кертеп, Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына кадәр, алга таба Мәскәү – Екатеринбург тимер юл линиясе буйлап, «Казан-2» транспортка күчеп утыру узелы территориясен кертеп, Ибраһимов проспекты Воровский урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ибраһимов проспектының җөп ягы буйлап Ямашев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ямашев проспектының так ягы буйлап Бондаренко урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Бондаренко урамының так ягы буйлап Чистай урамы белән кисешкәнгә кадәр, Чистай урамының так ягы буйлап Декабристлар урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Декабристлар урамының җөп ягы буйлап Лена урамы белән кисешкәнгә кадәр, Лена урамының җөп ягы буйлап Серов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Серов урамының так ягы буйлап Коләхмәтов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Коләхмәтов урамы буйлап Восстание урамына кадәр, алга таба,

Восстание урамын кисеп үтеп, Васильченко урамының җөп ягы буйлап, алга таба Казан шәһәре Мәскәү һәм Киров районнарының чиктәш чиге буйлап Васильченко урамы буенча «Водоканал» МУП кар эретү пунктына кадәр, алга таба көнчыгыш юнәлештә Тэц һәм Гудованцев урамнары киселешенә кадәр, алга таба Казан шәһәре Мәскәү һәм Авиатөзелеш районнарының чиктәш чиге буйлап Тэц һәм Хлебозавод урамнары киселешенә кадәр.

**7 нче Ибраһимов сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 53029

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Волгоград урамы, 32 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Яңа Савин районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Ибраһимов проспектының Гагарин урамы белән киселешеннән алып Гагарин урамының так ягы буйлап Октябрь урамы белән кисешкәнгә кадәр, Октябрь урамының җөп ягы буйлап, Октябрь урамы буенча 16, 18, 20, 22, 24, 26 нчы йортларны, Воровский урамы буенча 3а йортын, Короленко урамы буенча 107 нче, 103 нче йортларны кертеп, Короленко урамының җөп ягы буйлап Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына кадәр, тимер юл буйлап Фатыйх Әмирхан урамы белән кисешкәнгә кадәр, Фатыйх Әмирхан урамының так ягы буйлап, Фатыйх Әмирхан урамы буенча 18 нче, 22 нче йортларны һәм Маршал Чуйков урамы буенча 43, 49, 51, 53, 55, 57, 63, 63а йортларын кертеп, Ямашев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Ямашев проспектының җөп ягы буйлап «Татнефтепродукт» АЗСка (Ямашев проспекты, 29а йорты) кадәр, алга таба, Җиңү паркы территориясен кисеп үтеп, Маршал Чуйков урамы буенча 11 нче йортны кертеп, шул йортка кадәр, алга таба Маршал Чуйков урамының так ягы буйлап Восстание урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Восстание урамының җөп ягы буйлап Ибраһимов проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ибраһимов проспектының так ягы буйлап Гагарин урамы белән кисешкәнгә кадәр.

**8 нче Чуйков сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 54354

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Волгоград урамы, 32 нче йорт



Сайлау округына Казан шәһәре Яңа Савин районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Фатыйх Әмирхан урамы буенча 24 нче йорттан алып Фатыйх Әмирхан урамының җөп ягы буйлап Мәскәү – Екатеринбург тимер юлы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба тимер юл линиясе буйлап Казан шәһәре Совет районы чиге белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре Яңа Савин һәм Совет районнарының чиктәш чиге буйлап Ямашев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ямашев проспектының җөп ягы буйлап Фатыйх Әмирхан урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Фатыйх Әмирхан урамының җөп ягы буйлап, Фатыйх Әмирхан урамы буенча 18 нче, 22 нче йортларны һәм Маршал Чуйков урамы буенча 43, 49, 51, 53, 55, 57, 63, 63а йортларын кертмичә, Фатыйх Әмирхан урамы буенча 24 нче йортка кадәр.

**9 нчы Ямашев сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 56194

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Волгоград урамы, 32 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Яңа Савин районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Ибраһимов проспектының Восстание урамы белән киселешеннән алып Восстание урамының так ягы буйлап Маршал Чуйков урамына кадәр, Маршал Чуйков урамының җөп ягы буйлап, Маршал Чуйков урамы буенча 11 нче йортны кертмичә, шул йортка кадәр, алга таба, туры сызык буенча Җиңү паркын кисеп үтеп, Ямашев проспектына кадәр, алга таба Ямашев проспектының так ягы буйлап Казансу елгасы акваториясенә кадәр, алга таба Казансу елгасы яры буйлап Казан шәһәре Совет районы чиге белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре Яңа Савин һәм Совет районнарының чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре Вахитов районы чиге белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казансу елгасы акваториясе буйлап Ленин дамбасы белән кисешкәнгә кадәр, Ленин дамбасы буйлап Сибгат Хәким һәм Бондаренко урамнары кисешкәнгә кадәр, алга таба Бондаренко урамының җөп ягы буйлап, Бондаренко урамы буенча 6 нчы йортны кертмичә, Ямашев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ямашев проспектының җөп ягы буйлап Ибраһимов проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ибраһимов проспектының так ягы буйлап Восстание урамы белән кисешкәнгә кадәр.

## 10 нчы Шаляпин сайлау округы

Сайлаучылар саны – 59956

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Ипподром урамы, 17 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Идел буе районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: елга портының йөк причалы очыннан алып Идел елгасы яры буенча, Казан шәһәре Идел буе һәм Вахитов районнарының чиктәш чиге буйлап тимер юл линиясенә кадәр, алга таба тимер юл линиясе буйлап Кәрим Тинчурин бакчасы территориясенең көньяк чигенә кадәр, Кәрим Тинчурин бакчасы территориясе чиге буйлап Әхтәмов урамына кадәр, алга таба Әхтәмов урамының так ягы буйлап Сара Садыйкова урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Сара Садыйкова урамының җөп ягы буйлап Габдулла Тукай урамы белән кисешкәнгә кадәр, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Вахитов мәйданына кадәр, алга таба Вахитов мәйданыннан алып Эсперанто урамының так ягы буйлап Агрономия урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Агрономия урамының җөп ягы буйлап Даурия урамына кадәр, алга таба, Даурия урамын кисеп үтеп, Универсиада проспекты буйлап Танковая урамына кадәр, Танковая урамы буйлап Карбышев урамы белән кисешкәнгә кадәр, Карбышев урамының җөп ягы буйлап, Карбышев урамы буенча 33, 35, 43, 47/1 нче йортларны кертеп, Профессор Камай урамын кисеп үтеп, Профессор Камай урамы буенча 3 нче йортны кертеп, Карбышев урамы буйлап, 1 нче Калининград, 2 нче Калининград, 3 нче Калининград, 4 нче Калининград, 1 нче Хәсән геройлары, 2 нче Хәсән геройлары урамнары буенча йортларны, шулай ук Карбышев урамы буенча 57, 59, 61, 65, 67 нче йортларны кертеп, Академик Парин урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Академик Парин урамы буйлап Оренбург тракты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Оренбург трактының җөп ягы буйлап, Лазурная, Медиклар, Уютная, Юкә урамнарын кертеп, көнчыгыш юнәлештә («Ромашка» коммерциясез бакчачылык ширкәтен кертеп) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чигенә кадәр, алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буйлап Идел елгасына кадәр, алга таба төньяк юнәлештә Идел елгасы яры буйлап елга портының йөк причалы очына кадәр.



## 11 нче Горки сайлау округы

Сайлаучылар саны – 57769

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Ипподром урамы, 17 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Идел буе районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Танковая урамының Хөсәен Мәүлетов урамы белән киселешеннән алып Казан шәһәре Идел буе һәм Совет районнарының чиктәш чиге буйлап Җиңү проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Җиңү проспекты буйлап Академик Завойский урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Академик Завойский урамының җөп ягы буйлап Юлиус Фучик урамы белән кисешкәнгә кадәр, Юлиус Фучик урамының так ягы буйлап Рихард Зорге урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Рихард Зорге урамының так ягы буйлап Җиңү проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Җиңү проспектының так ягы буйлап Оренбург тракты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Оренбург трактының так ягы буйлап Академик Парин урамына кадәр, Академик Парин урамы буйлап Карбышев урамы белән кисешкәнгә кадәр, Карбышев урамының так ягы буйлап, Карбышев урамы буенча 57, 59, 61, 65, 67 нче йортларны кертмичә һәм 63 нче йортны (1, 2 корпусларны) кертеп, шулай ук 1 нче Калининград, 2 нче Калининград, 3 нче Калининград, 4 нче Калининград, 1 нче Хәсән геройлары, 2 нче Хәсән геройлары урамнары буенча йортларны кертмичә, Карбышев урамының так ягы буйлап, Карбышев урамы буенча 33, 35, 43, 47/1 нче йортларны, шулай ук Профессор Камай урамы буенча 3 нче йортны кертмичә, Танковая урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Танковая урамы буйлап Хөсәен Мәүлетов урамы белән кисешкәнгә кадәр.

## 12 нче Габишев сайлау округы

Сайлаучылар саны – 60598

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Ипподром урамы, 17 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Идел буе районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Академик Завойский урамының Юлиус Фучик урамы белән киселешеннән алып Академик Завойский урамының җөп ягы буенча Комиссар Габишев урамы белән кисешкәнгә кадәр, Казан шәһәре Идел буе

һәм Совет районнарының чиктәш чиге буйлап, Академик Завойский урамы буенча 21 нче йортны, төзелә торган 6/4 нче йортны кертеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чигенә кадәр, алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буенча, алга таба көнбатыш юнәлештә Оренбург трактының җөп ягы буйлап («Ромашка» коммерциясез бакчачылык ширкәтен кертмичә), Лазурная, Медиклар, Уютная, Юкә урамнарын кертмичә, Җиңү проспекты белән кисешкәнгә кадәр. Алга таба Җиңү проспектының җөп ягы буйлап Рихард Зорге урамы белән кисешкәнгә кадәр, Рихард Зорге урамының җөп ягы буйлап Юлиус Фучик урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Юлиус Фучик урамының җөп ягы буйлап Академик Завойский урамы белән кисешкәнгә кадәр.

### 13 нче Дәрвишләр сайлау округы

Сайлаучылар саны – 53831

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Шуртыгин урамы, 1 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Совет районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Мәскәү – Түбән Новгород – Казан – Уфа (М-7 «Волга») федераль трассасының 812 нче км ноктасыннан алып Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буйлап, Нагорная, Совхоз, Беркутов, Зеленая, Пикин, Современников, Заречная урамнарын кертеп, Мәскәү – Түбән Новгород – Казан – Уфа (М-7 «Волга») федераль трассасы Завод урамы белән кисешкән ноктага кадәр, алга таба көнбатыш юнәлештә, Алмагач, Алматау, Алчәчәк, Аяз, Балантау, Бәхетле урамнарын, Бәхетле тыкрыгын, Беркутов, Возрождение, Гидромонтажниклар, Звездная, Читек, Кристалл, Кулагин, Наратбаш, Сандугач, Саф, Сафлык, Тагаевская, Ташлыяр, Тормыш, Травная (1 – 28 нче йортлар), Тургай, Энҗе, Январь (1 – 20 нче йортлар) урамнарын кертеп, Возрождение урамына кадәр, «Нокса-2» бакчачылык ширкәтенә кадәр, алга таба «Нокса-2» бакчачылык ширкәте чикләре һәм Царицыно зираты буйлап Нокса елгасына кадәр, алга таба Нокса елгасы буйлап Дорожный тыкрыгы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Дорожный тыкрыгы буйлап Җиңү проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Җиңү проспектының җөп ягы буйлап, 2 нче Азино урамы буенча 1, 1а, 1б, 1в, 1г, 1д, 1е йортларын кертеп, Академик Арбузов урамы буенча 48 нче йортка кадәр, алга таба Яңа Азино урамының җөп ягы буйлап Артиллерия урамы белән кисешкәнгә



кадәр, Артиллерия урамының так ягы буйлап Краснооктябрьск урамы белән кисешкәнгә кадәр, Краснооктябрьск урамының так ягы буйлап Александр Попов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Александр Попов урамының так ягы буйлап, Академик Кирпичников урамы буенча 15 нче, 17 нче йортларны, Себер тракты буенча 16 нчы, 18 нче йортларны, Александр Попов урамы буенча 11 нче, 13 нче йортларны кертмичә, Себер тракты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Себер трактының җөп ягы буйлап, Троицкий Лес урамы буенча йортларны кертеп, Себер тракты буенча 32 нче йортка кадәр, Казан шәһәре Яңа Савин районы чиге белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре Совет һәм Яңа Савин районнарының чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Совет районнарының чиктәш чиге белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Совет районнарының чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чигенә кадәр, алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буйлап Мәскәү – Түбән Новгород – Казан – Уфа (М-7 «Волга») федераль трассасының 812 нче км ноктасына кадәр.

### 14 нче Пионер сайлау округы

Сайлаучылар саны – 55314

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Шуртыгин урамы, 1 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Совет районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Себер тракты һәм Александр Попов урамы киселешеннән алып, Себер тракты буенча 16 нчы, 18 нче йортларны, Александр Попов урамы буенча 11 нче, 13 нче йортларны, Академик Кирпичников урамы буенча 15 нче, 17 нче йортларны кертеп, Краснооктябрьск урамына кадәр, алга таба Краснооктябрьск урамының җөп ягы буйлап Артиллерия урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Артиллерия урамының җөп ягы буйлап, алга таба Яңа Азино урамының так ягы буйлап, Каспийская урамы буенча 33 нче йортны кертеп, Академик Арбузов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Җиңү проспекты буйлап, 2 нче Азино урамы буенча 1, 1а, 1б, 1в, 1г, 1д, 1е йортларын кертмичә, Дорожный тыкрыгы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Дорожный тыкрыгы буйлап Нокса елгасына кадәр, алга таба Нокса елгасы буйлап Царицыно зиратының көньяк чиге белән кисешкәнгә кадәр, алга

таба Царицыно зиратының көньяк чиге һәм «Нокса-2» бакчачылык ширкәте буйлап, Алмагач, Алматау, Алчәчәк, Аяз, Балантау, Бәхетле урамнарын, Бәхетле тыкрыгын, Беркутов, Возрождение, Гидромонтажниклар, Звездная, Читек, Кристалл, Кулагин, Наратбаш, Сандугач, Саф, Сафлык, Тагаевская, Ташлыяр, Тормыш, Травная (1 – 28 нче йортлар), Тургай, Энҗе, Январь (1 – 20 нче йортлар) урамнарын кертмичә, Тургай урамына кадәр, алга таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә, Нагорная, Совхоз, Беркутов, Зеленая, Пикин, Современников, Заречная урамнарын кертмичә, Мәскәү – Түбән Новгород – Казан – Уфа (М-7 «Волга») федераль трассасы Завод урамы белән кисешкән ноктага кадәр, алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буйлап Казан шәһәре Идел буе һәм Совет районнары территорияләренең Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чигендәге тоташу ноктасына кадәр, алга таба Казан шәһәре Совет һәм Идел буе районнарының чиктәш чиге буйлап Гали Динмөхәммәтов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Гали Динмөхәммәтов урамы буйлап, Солнечная, Обновление, Наклонная, Туры урамнарын, Ноксинский тыкрыгын, Яфраклы тыкрыгын кертеп, Ноксинский спуск урамы Минская урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Минская урамы буйлап Юлиус Фучик урамы белән кисешкәнгә кадәр, Юлиус Фучик урамы буйлап Академик Сахаров урамына кадәр, алга таба Академик Сахаров урамының җөп ягы буйлап Рәшит Ваһапов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Рәшит Ваһапов урамының җөп ягы буйлап Магистраль урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Магистраль урамы буенча 16а йортына кадәр, алга таба, Академик Глушко урамы буенча 22а, 23, 33 нче йортларны, Хәйдәр Бигичев урамы буенча 16, 18, 15 нче йортларны, Җиңү проспекты буенча 174 нче, 172 нче йортларны кертеп, Җиңү проспекты буйлап Альберт Камалиев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Альберт Камалиев проспекты буйлап Патрис Лумумба урамы белән кисешкәнгә кадәр, Патрис Лумумба урамы буйлап, Патрис Лумумба урамы буенча 38а, 47, 49, 57 нче йортларны кертмичә, Искра урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Искра урамы буйлап, Искра урамы буенча 151/1 нче йортны кертеп, Николай Ершов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Николай Ершов урамының җөп ягы буйлап Себер тракты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Себер трактының җөп ягы буйлап Себер тракты буенча 16 нчы йортка кадәр.



## 15 нче Азино сайлау округы

Сайлаучылар саны – 54592

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Шуртыгин урамы, 1 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Совет районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Җиңү проспекты буенча 168 нче, 166 нчы йортлардан алып, Хәйдәр Бигичев урамы буенча 13а, 13, 12, 14 нче йортларны, Академик Глушко урамы буенча 31, 21, 22 нче йортларны, Азино-1 торак комплексының Магистраль урамы буенча 20 нче, 18а йортларын кертеп, Магистраль урамы буйлап Рәшит Ваһапов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Рәшит Ваһапов урамының так ягы буйлап Академик Сахаров урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Академик Сахаров урамының так ягы буйлап Юлиус Фучик урамына кадәр, Юлиус Фучик урамы буйлап Минская урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Минская урамы буйлап Нокса авышлыгы урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Гали Динмөхәммәтов урамы буйлап, Солнечная, Обновление, Наклонная, Туры урамнарын, Ноксинский тыкрыгын, Яфраклы тыкрыгын кертмичә, Академик Завойский урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре Совет һәм Идел буе районнарының чиктәш чиге буйлап Академик Завойский урамының так ягы буйлап, Академик Завойский урамы буенча 21 нче йортны, төзелә торган 6/4 нче йортны кертмичә, Җиңү проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Җиңү проспекты буйлап, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник инфекция больницасы» сәламәтлек саклау дәүләт автономияле учреждениесе территориясен, Җиңү проспекты буенча 57а йортын, төзелә торган 57-1 нче йортны кертеп, Альберт Камалиев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Җиңү проспекты буенча 168 нче йортка кадәр.

## 16 нчы Гвардия сайлау округы

Сайлаучылар саны – 55159

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Казан шәһәре, Шуртыгин урамы, 1 нче йорт

Сайлау округына Казан шәһәре Совет районы территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Акаде-

мик Арбузов урамы һәм Себер трактының киселешеннән алып Себер трактының так ягы буйлап Николай Ершов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Николай Ершов урамының так ягы буйлап Искра урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Искра урамы буйлап, Искра урамы буенча 1/151 нче йортны кертмичә, Патрис Лумумба урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Патрис Лумумба урамы буйлап, Патрис Лумумба урамы буенча 38а, 47, 49, 57 нче йортларны кертеп, Альберт Камалиев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Альберт Камалиев проспекты буйлап, алга таба Җиңү проспекты буйлап, Крылов, Скрябин, Рылеев, Родина урамнарын кертеп, Казан шәһәре Совет һәм Идел буе районнарының чиктәш чигенә кадәр, алга таба Казан шәһәре Совет һәм Идел буе районнарының чиктәш чиге буйлап Хөсәен Мәүлетов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Хөсәен Мәүлетов урамы буйлап Танковая урамы белән кисешкәнгә кадәр, Танковая урамы буйлап, алга таба, Комаров, Латышских Стрелков, Отрадная урамнарын кертеп, Әмәт магистраленә кадәр, алга таба тимер юл линиясе буйлап Казан шәһәре Совет һәм Вахитов районнарының чиктәш чиге буенча, Казан шәһәре Совет һәм Яңа Савин районнарының чиктәш чиге буенча Казансу елгасы акваториясе буйлап, Троицкий Лес урамын кертмичә, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» сәламәтлек саклау шәһәр автономияле учреждениесе территориясен кертеп, Себер тракты һәм Академик Арбузов урамы кисешкәнгә кадәр.

**17 нче Комсомол сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 54434
Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 56 нчы йорт

Сайлау округына Чаллы шәһәре территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Аркылы урамы һәм Казан проспектының киселешеннән алып Аркылы урамы буйлап, Аркылы урамы буенча торак йортларны һәм «Тукай үзәк район больницасы» сәламәтлек саклау дәүләт автономияле учреждениесе территориясен кертеп, Һади Такташ урамына кадәр, Һади Такташ урамы буенча 2, 8, 14а, 14б, 14в, 18, 19 нчы йортларны кертеп, Сарман трактына кадәр, алга таба Сарман тракты буйлап, Сарман тракты буенча 4, 6, 8, 10, 12, 14/15, 16 нчы йортларны кертеп, Аэродромная урамына кадәр, «Замелекесье» микро-



районын кертеп, Гостев урамы буйлап Габдулла Тукай Яр буе урамы белән кисешкәнгә кадәр, Габдулла Тукай Яр буе урамы буйлап Мәләкәс елгасы акваториясе буенча Казан проспектына кадәр, алга таба Казан проспекты буйлап Әлмәт тракты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Әлмәт тракты буйлап «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап, Сидоровка микрорайонын, Суар торак районы йортларын кертеп, Сарман трактына кадәр, Сарман тракты буйлап Казан проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан проспекты буйлап Аркылы урамы белән кисешкәнгә кадәр.

**18 нче Мәләкәс сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 57336
Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 56 нчы йорт

Сайлау округына Чаллы шәһәре территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Һади Такташ урамы белән Сарман тракты киселешеннән Сарман тракты буенча 4, 6, 8, 10, 12, 14/15, 16 нчы йортларны кертмичә һәм 15 нче йортны, шулай ук Кызыл Чаллы, Элеватор тавы микрорайоннарын кертеп, Мәләкәс елгасы һәм Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 35/7, 35/9/1, 36/4/4, 36/8/3, 36/8/4, 36/8/5 нче төзелеш адреслары белән йортларны, Беренче Береговая, Икенче Береговая, 1 нче проезд, 2 нче проезд, 3 нче проезд, 4 нче проезд, 5 нче проезд, 6 нчы проезд, Порт урамнары буенча йортларны кертеп, Раскольников урамы буенча 44 нче йортка кадәр, алга таба Раскольников урамы буенча 33, 31, 29, 19 нчы йортларны, Илдар Маннанов урамы буенча 6 нчы, 8 нче йортларны, Чулман проспекты буенча 11, 13, 17/2, 19, 21 нче йортларны кертеп, Академик Королев урамына кадәр, Академик Королев урамының так ягы буенча, Орловка микрорайонын кертеп, Машина төзелеше урамына кадәр, алга таба, Орловка божрасын кисеп үтеп, Казан проспекты буенча 27 нче квартал, 28 нче квартал, Рябинушка микрорайоны йортларын кертеп, Аркылы урамына кадәр, Аркылы урамы буенча йортларны кертмичә, Аркылы урамы буйлап Һади Такташ урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Һади Такташ урамы буенча 19 нчы йортны кертмичә, Һади Такташ урамы белән Сарман тракты киселешенә кадәр.

## 19 нчы Үзәк сайлау округы

Сайлаучылар саны – 59243

Территория (округ) сайлау комиссиясенең урнашкан урыны – Чаллы шәһәре, Энтузиастлар бульвары, 11 нче йорт

1. «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 420241-6 номерлы федераль закон проектын (ата-анасы билгеле булмаган балаларга туендыручысын югалткан очракта социаль пенсиягә хокук бирү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3369-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 68. «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмуртия Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмуртия Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Удмуртия Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3370-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 69. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына дәүләт җир күзәтчелеген камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 421545-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына дәүләт җир күзәтчелеген камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 421545-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3371-IV ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 70. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль законның $19^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Рязань өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль законның $19^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Рязань өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Рязань өлкә Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3372-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 71. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 12 һәм 20 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Саха (Якутия) Республикасы Дәүләт Собраниесенең (Ил Тумэн) закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 12 һәм 20 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Саха (Якутия) Республикасы Дәүләт Собраниесенең (Ил Тумэн) закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Саха (Якутия) Республикасы Дәүләт Собраниесенә (Ил Тумэн) җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3373-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 72. «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 415028-6 номерлы федераль закон проекты хакында (этил спиртын һәм алкоголь продукциясен оешманың бер аерым бүлекчәсе тарафыннан җитештерүне тыюны төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 415028-6 номерлы федераль закон проектын (этил спиртын һәм алкоголь продукциясен оешманың бер аерым бүлекчәсе тарафыннан җитештерүне тыюны төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3374-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 73. «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 421531-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт кадастр бәяләвен камилләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 421531-6 номерлы федераль закон проектын (дәүләт кадастр бәяләвен камилләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3375-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 74. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 400896-6 номерлы федераль закон проекты турында (көнкүреш билгеләнешендәге пиротехника әйберләренә янгын куркынычсызлыгы буенча өстәмә таләпләр билгеләү өлешендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен төгәлләштерү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 400896-6 номерлы федераль закон проектын (көнкүреш билгеләнешендәге пиротехника әйберләренә янгын куркынычсызлыгы буенча өстәмә таләпләр билгеләү өлешендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен төгәлләштерү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3376-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 75. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 419909-6 номерлы федераль закон проекты турында (Кодексның 20.1, 20.20 һәм 20.21 статьяларында каралган хокук бозуларны кылган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 419909-6 номерлы федераль закон проектын (Кодексның 20.1, 20.20 һәм 20.21 статьяларында каралган хокук бозуларны кылган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3377-IV ДС



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 76. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 419182-6 номерлы федераль закон проекты турында (балигъ булмаганнарга алкоголь продукциясен ваклап саткан өчен юридик затларга административ җаваплылыкны көчәйтү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 419182-6 номерлы федераль закон проектын (балигъ булмаганнарга алкоголь продукциясен ваклап саткан өчен юридик затларга административ җаваплылыкны көчәйтү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3378-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 77. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 420986-6 номерлы федераль закон проекты турында (Кодексның 14 бүлегенә административ хокук бозуларның яңа составларын өстәү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 420986-6 номерлы федераль закон проектын (Кодексның 14 бүлегенә административ хокук бозуларның яңа составларын өстәү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3379-IV ДС

## 78. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 418857-6 номерлы федераль закон проекты турында (һава судноларын эксплуатацияләүдә иминлек кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 418857-6 номерлы федераль закон проектын (һава судноларын эксплуатацияләүдә иминлек кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3380-IV ДС





## 79. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына миграция өлкәсендәге законнарны бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 419207-6 номерлы федераль закон проекты турында (чакырылган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат Россия Федерациясендә булган чорда, аларга карата чакырган як тарафыннан матди, медицина һәм торак ягыннан тәэмин итү чаралары күрелмәгән өчен административ җаваплылыкка тартыла торган субъектлар исемлегенә физик затларны кертү турында, шулай ук Россия Федерациясе миграция законнарын төрлечә бозган өчен салына торган административ штрафлар күләмнәрен арттыру хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына миграция өлкәсендәге законнарны бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 419207-6 номерлы федераль закон проектын (чакырылган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат Россия Федерациясендә булган чорда, аларга карата чакырган як тарафыннан матди, медицина һәм торак ягыннан тәэмин итү чаралары күрелмәгән өчен административ җаваплылыкка тартыла торган субъектлар исемлегенә физик затларны кертү турында, шулай ук Россия Федерациясе миграция законнарын төрлечә бозган өчен салына торган административ штрафлар күләмнәрен арттыру хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3381-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 80. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 26.7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 403676-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозу турындагы эш буенча дәлил итеп таныла торган документларның эчтәлеген төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 26.7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 403676-6 номерлы федераль закон проектын (административ хокук бозу турындагы эш буенча дәлил итеп таныла торган документларның эчтәлеген төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3382-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 81. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 395531-6 номерлы федераль закон проекты турында (хайваннарга карата кырыс мөнәсәбәтне пропагандалаган өчен административ җаваплылык билгеләү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 395531-6 номерлы федераль закон проектын (хайваннарга карата кырыс мөнәсәбәтне пропагандалаган өчен административ җаваплылык билгеләү турында) хупларга.



2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3383-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 82. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясындагы 2 өлешенә һәм 28.7 статьясындагы 1 өлешенә үзгәрешләр кертү хакында» 421518-6 номерлы федераль закон проекты турында (Кодексның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясындагы 2 өлешенә һәм 28.7 статьясындагы 1 өлешенә үзгәрешләр кертү хакында» 421518-6 номерлы федераль закон проектын (Кодексның аерым нигезләмәләрен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3384-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 83. «Шәхси белешмәләр турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 416052-6 номерлы федераль закон проекты турында (оператор кушуы буенча шәхси белешмәләрне эшкәртү тәртибен төгәлләштерү, шулай ук эшкәртелә торган шәхси белешмәләрнең иминлеген тәэмин итү таләпләрен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Шәхси белешмәләр турында» Федераль законга һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 416052-6 номерлы федераль закон проектын (оператор кушуы буенча шәхси белешмәләрне эшкәртү тәртибен төгәлләштерү, шулай ук эшкәртелә торган шәхси белешмәләрнең иминлеген тәэмин итү таләпләрен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3385-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 84. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 428889-6 номерлы федераль закон проекты хакында (террорчылыкка каршы көрәшне камилләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 428889-6 номерлы федераль закон проектын (террорчылыкка каршы көрәшне камилләштерү өлешендә) хупларга.



2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3386-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 85. «Оператив-эзләү эшчәнлеге турында» Федераль законның 8 һәм 15 статьяларына һәм «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 306542-6 номерлы федераль закон проекты турында (ачык оператив-эзләү чараларын башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын саклауда прокурор күзәтчелегенең нәтиҗәлелеген арттыру өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Оператив-эзләү эшчәнлеге турында» Федераль законның 8 һәм 15 статьяларына һәм «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 306542-6 номерлы федераль закон проектын (ачык оператив-эзләү чараларын башкарганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын саклауда прокурор күзәтчелегенең нәтиҗәлелеген арттыру өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3387-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 86. «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 421465-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 421465-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3388-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 87. «Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 415620-6 номерлы федераль закон проекты турында (эчке эшләр органнарының һәлак (вафат) булган гаилә әгъзаларына ай саен акчалата компенсация билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 415620-6 номерлы федераль закон проектын (эчке эшләр органнарының һәлак (вафат) булган гаилә әгъзаларына ай саен акчалата компенсация билгеләү хакында) хупларга.



2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3389-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 88. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышына – Корылтаена җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3390-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 89. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның $12^5$ статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның $12^5$ статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышына – Корылтаена җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3391-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 90. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының нигезләре турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасын хупларга.



2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышына – Корылтаена җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3392-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 91. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының $53^1$ статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының $53^1$ статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышының – Корылтаеның закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышына – Корылтаена җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3393-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 92. «Россия Федерациясе гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 399590-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия балаларын әлеге балаларга туган булмаган чит ил гражданнарының уллыкка алуын тыю өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 399590-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия балаларын әлеге балаларга туган булмаган чит ил гражданнарының уллыкка алуын тыю өлешендә) хупламаска.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3394-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 93. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 357 статьясына үзгәреш кертү турында» 403431-6 номерлы федераль закон проекты хакында (дәүләт хезмәт инспекторларына судка мөрәҗәгать итү хокукы бирү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 357 статьясына үзгәреш кертү турында» 403431-6 номерлы федераль закон проектын (дәүләт хезмәт инспекторларына судка мөрәҗәгать итү хокукы бирү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3395-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 94. «Россия Федерациясендә аш тозын йодлаштыру турында» 410102-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә аш тозын йодлаштыру турында» 410102-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 феврале
№ 3396-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 95. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның 27 февралендәге чираттан тыш утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның 27 февралендәге чираттан тыш утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының (парламентының) Кырым Автономияле Республикасы халыкларына мөрәҗәгате турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 27 феврале
№ 3399-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 96. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының (парламентының) Кырым Автономияле Республикасы халыкларына мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының (парламентының) Кырым Автономияле Республикасы халыкларына мөрәҗәгатен кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Кырым Автономияле Республикасы Югары Советына Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан түбәндәге составта делегация оештырырга:

Вәлиев Разил Исмәгыйль улы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе;

Бударин Виктор Николаевич – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты;

Закиров Ринат Зиннур улы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе;

Миңнуллин Роберт Мөгаллим улы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты;

Ногманов Рафил Габдерәфыйк улы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары.

Делегациягә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кабул ителгән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән позициясен Кырым Автономияле Республикасы парламентарийлары игътибарына җиткерүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинга, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы Рәисе В.И. Матвиенкога, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга, Украина Югары Радасына һәм Кырым Автономияле Республикасы Югары Советына җибәрергә.

4. Әлеге карарны республиканың массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 27 феврале
№ 3400-IV ДС



Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының (парламентының) 2014 елның 27 февралендәге
3400-IV номерлы карарына
кушымта

## Татарстан Республикасы Дәүләт Советының (парламентының) Кырым Автономияле Республикасы (Украина) халыкларына мөрәҗәгате

Иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисадый вәзгыятькә тирән борчылып, көч куллануны гаепләп һәм «мәйдан» аша аерым төркемнәр файдасына сәяси карарлар кабул итүне, бу омтылышларның Кырым Автономияле Республикасы территориясенә үтеп керүен булдырмаска өндәп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (парламенты):

1. Барлык каршы торучы якларны дәүләт эчендә килеп туган каршылыкларны тыныч юл белән, сәяси-дипломатик ысуллар кулланып, хәл итәргә чакыра.

2. Кырым Автономияле Республикасының барлык халыкларын – украиннарны, русларны, Кырым татарларын милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклап калырга, конфликтны хәл итүнең радикаль алымнарыннан катгый баш тартырга чакыра.

3. Кырым Автономияле Республикасы хакимиятен дәүләт эчендәге конфликтта барлык катнашучыларның көч куллану алымнарын кискен гаепләргә чакыра.

Без конфликтны Кырым автономиясенең конституциячел-хокукый статусы тайпылышсыз сакланган килеш хәл итүне хуплыйбыз.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (парламенты) конфликтларны җайга салу барышында законлы тыныч юлларга өстенлек бирергә, кеше һәм граждан хокукларын үтәүдә Берләшкән Милләтләр Оешмасының төп документларында күрсәтелгән какшамас принципларны кулланырга кирәк дип саный.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 97. Халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә Лениногорск муниципаль районы эш тәҗрибәсе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзаларының һәм чакырылганнарның докладларын һәм чыгышларын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы түбәндәгеләрне билгеләп үтә. Республикада торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә берничә озак сроклы программаларны, аеруча 2004 елның 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2004 – 2010 елларга Татарстан Республикасы торак-коммуналь комплексын реформалау һәм модернизацияләү программасын, гамәлгә ашыру торак-коммуналь өлкәдә вәзгыятьне тотрыкландырырга, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын, халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итүнең торак-коммуналь системалары эшенең нәтиҗәлелеген һәм ышанычлылыгын арттырырга мөмкинлек бирде, бу зыянга эшли торган оешмалар өлеше кимүдә, түләүләр җыю артуда, төп фондларның физик яктан тузуы кимүдә, торак фондында төзекләндерү дәрәҗәсе артуда, капма-каршы субсидияләүне бетерүдә, күпфатирлы йортлар белән идарә итү системалары нигезен булдыруда һәм торак өлкәсендә үзидарәне үстерүдә, халыкның коммуналь хезмәтләр күрсәтүдән файдалану күләмнәре кимүдә чагылды.

Карала торган мәсьәлә кысаларында Лениногорск муниципаль районында торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауның һәм модернизацияләүнең кайбер уңай нәтиҗәләрен билгеләп үтәргә кирәк.

Лениногорск муниципаль районында җылылык челтәрләренең тузу дәрәҗәсе 2012 елда 80 % тәшкил итә иде. Лениногорск шәһәрен җылылык белән ышанычлы һәм сыйфатлы тәэмин итү максатларында «2013 – 2014 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск районы җылылык хуҗалыгын модернизацияләү, яңадан төзү һәм техник яктан җиһазландыру» (тариф чыганагы акчаларын җәлеп итмичә) инвестиция программасы эшләнде. Программа чараларын финанслау күләме 481 млн. сум тәшкил итә. 2013 елда беренче этапны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 5 блок-модуль котельня төзелде, 7 км җылылык челтәре үткәрелде, 75 фатир индивидуаль җылыту системасына күчерелде. Еллык икътисадый нәтиҗә 18,43 млн. сум булыр дип көтелә.



2013 елда йөз процентка якын (99,9 %) түләүләр җыю дәрәҗәсенә ирешү Лениногорск муниципаль районында торак-коммуналь хезмәтләр (алга таба – ТКХ) күрсәткән өчен халыктан җыелган түләүләр дәрәҗәсен арттыру буенча чаралар комплексының нәтиҗәсе булып тора. 2013 елда Лениногорск муниципаль районында халыктан торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен җыелган түләүләр дәрәҗәсе уртача республика буенча җыелган түләүләрдән 1 %ка югары.

Лениногорск муниципаль районында гомумйорт һәм индивидуаль исәпләү приборлары белән җиһазландыру дәрәҗәсе республикада иң югарысы (кайнар су белән тәэмин итү буенча – 94,4 % (Татарстан Республикасы буенча – 84,7 %); салкын су белән тәэмин итү буенча – 94,9 % (Татарстан Республикасы буенча – 82,2 %), электр белән тәэмин итү буенча – 99,5 % (Татарстан Республикасы буенча – 93,3 %). Ләкин исәпләү приборлары белән җиһазландыруның югары процент булуы коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләүне дөрес исәпләүне гарантияләми. Мәсәлән, республиканың кайбер муниципаль берәмлекләрендә, исәпләү приборлары куелган булса да, түләүне коммуналь хезмәтләр күрсәтү нормативлары буенча исәпләү тәҗрибәсе гамәлдә.

Лениногорск муниципаль районында идарә итүче оешмалар вәкилләренең индивидуаль исәпләү приборларын, аларның сакланышын тәэмин итеп, карый алу мөмкинлеге техник яктан уңай хәл ителгән, бу коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне исәпләүнең үтә күренмәле булуына, түләүләрне җыеп бетермәү, шулай ук күпфатирлы йортларда подвалларны техник һәм санитария-гигиена нормативлары буенча карап тоту мәсьәләләрен хәл итүгә ярдәм итә.

Татарстан Республикасында торак-коммуналь өлкәдә ирешелгән уңай нәтиҗәләргә карамастан, хәл ителәсе мәсьәләләр кала бирә, бу халыкта урынлы канәгатьсезлек тудыра. 2013 елда торак-коммуналь темага шикаятьләр мөрәҗәгатьләр саны буенча беренче урында тора, бу дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эш нәтиҗәлелеген арттыруны таләп итә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

I. Лениногорск муниципаль районының приборлар ярдәмендә исәпләүне оештыру, торак-коммуналь хезмәтләр

күрсәтүдән файдалануның һәм халыктан түләүләр җыюның үтә күренмәлелеген тәэмин итү юлы белән халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын арттыру өлешендәге эш тәҗрибәсен уңай дип танырга.

II. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

торак-коммуналь хезмәтләр өчен үтә күренмәле һәм куллану-чыга аңлаешлы исәп-хисап системасы булдыру чаралары күрергә:

торак-коммуналь хуҗалыкта түләмәүләр һәм бурычлар проблемаларының энергия ресурслары белән тәэмин итүчеләр һәм идарәче оешмалар арасында исәп-хисапларда килеп чыга торган дисбаланслар өлешендә сәбәпләрен анализларга һәм аларны законнар белән җайга салу буенча тәкъдимнәр әзерләргә;

Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасын булдыру эшен дәвам итәргә;

Татарстан Республикасында счет-фактураның билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм милекчеләргә түләүләрнең дөреслеген тикшереп тору мөмкинлеге бирә торган бердәй рәвешен кертергә;

1.2. Халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә, аеруча күпфатирлы йортлар белән идарә итү хезмәтләре күрсәтүдә, оптимизацияләү һәм конкуренцияне үстерү эшен дәвам итәргә. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендәге вәзгыятьне анализларга һәм, кирәк булса, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бер идарәче оешма, торак милекчеләре ширкәте, торак-төзелеш кооперативы яисә башка махсуслашкан кулланучылар кооперативы составында күпфатирлы йортлар белән оптималь идарә итү нормаларын билгели торган норматив хокукый актларына, милекчеләр һәм идарәче оешмалар мәнфәгатьләре нисбәтен саклау кирәклеген истә тотып, үзгәрешләр кертергә;

1.3. Коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә тарифларның артуын туктатып тору чаралары күрергә:

коммуналь ресурсларга озак вакытлы тарифлар билгеләүне тәэмин итәргә;

коммуналь өлкәдә тариф чыганакларыннан башка инвестиция программалары эшләгәндә дәүләти-хосусый партнерлык тәҗрибәсен кулланырга;

1.4. Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсенә модернизацияләү һәм коммуналь хуҗалык объектларының энергия нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләрен хәл итүгә хосусый инвестицияләр җәлеп итү өчен уңайлы шартлар тудыру эшен дәвам итәргә;



1.5. Коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында эшне башкаручы белән идарәче оешма, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яисә башка махсуслашкан кулланучылар кооперативы исеменнән төзелгән шартнамә һәм күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең, торак милекчеләре ширкәте әгъзаларының, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслашкан кулланучылар кооперативының гомуми җыелышында исәп-хисапларны мондый юл белән ясауга көчү турында кабул ителгән карар булган очракта, күпфатирлы йортларда торак урыннары милекчеләренең коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүләрне ресурслар белән тәэмин итә торган оешманың үзенә кертү юлы белән халыкка коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәчел мөнәсәбәтләрне оптимизацияләү мөмкинлеген өйрәнергә.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү буенча уңай эш тәҗрибәсен гомумиләштерергә һәм таратырга.

3. Җирлекләр һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары:

3.1. 2014 елда җирлекләрнең, шәһәр округларының су кертү, су һәм җылылык белән тәэмин итү схемаларын раслауны төгәлләргә һәм коммуналь комплекс оешмалары тарафыннан инвестиция программалары һәм җылылык энергиясен исәпләгәндә ягулыкның чагыштырма чыгымнары һәм технологик югалту нормативларын кабул итүне тәэмин итәргә;

3.2. Коммуналь комплекс объектларын дәүләти-хосусый партнерлык, концессия килешүләре механизмын кулланып, коммерциячел әйләнешкә актив җәлеп итү чаралары күрергә;

3.3. Лениногорск муниципаль районының фатирларны, ябык подвалларга индивидуаль исәпләү приборлары урнаштырып, индивидуаль вертикаль торбалар буенча су белән тәэмин итүнең аерым линияләренә күчерү тәҗрибәсен өйрәнергә;

3.4. Күрсәткечләре читтән торып алына торган энергия ресурсларын исәпләү приборлары кую мөмкинлеген һәм аларның икътисадый максатка туры килүен өйрәнергә;

3.5. Идарәче оешмалар һәм торак милекчеләре ширкәте эшчәнлеген, шул исәптән торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүләрнең нигезле булуын тикшереп торуны көчәйтергә;

3.6. Муниципаль берәмлектә торак урыны һәм (яки) коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен алты айдан артыграк түләмәүгә бәйле рәвештә торак урыннарыннан чыгарылган гражданнарны

күчерү өчен маневр фонды булдыру яки булганыннан файдалану мөмкинлеген карарга.

III. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты:

торак-коммуналь хуҗалыкта түләмәүләр һәм бурычлар проблемасын законнар белән җайга салу мониторингы эшен дәвам итәргә;

2014 елның IV кварталында комитет утырышында әлеге карарның үтәлешен карарга.

IV. «Татмедиа» ачык акционер җәмгыятькә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә уңай эш тәҗрибәсен массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәкъдим итәргә.

V. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының күчмә утырышында катнашучыларның Татарстан Республикасында торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү сыйфатын, торак-коммуналь комплексның эш нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәрен (кушымта итеп бирелә) гамәлгә ашыруның максатка ярашлы булуын өйрәнү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

VI. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары А.П. Гусевка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 31 гыйнвары
№ 3308-IV ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2014 елның 31 гыйнварындагы
3308-IV ДС номерлы карарына
кушымта

## Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының «Халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә Лениногорск муниципаль районы эш тәҗрибәсе турында» мәсьәләсе буенча күчмә утырышында катнашучыларның тәкъдимнәре

1. «Коммуналь фонд» төзү концепциясен эшләргә.

2. Энергия сервисы контрактларын төзү тәҗрибәсен киңәйтергә.



3. Күпфатирлы йортларда урыннар милекчесенә ресурслар белән тәэмин итүгә турыдан-туры килешүләр төзүне йөкләргә.

4. Түләүләр тәртибен гамәлдәге законнарга туры китерергә һәм тотылган коммуналь ресурслар (шул исәптән тотылган җылылык энергиясе өчен) өчен түләүләр тәртибенең гамәлдәге законнарга туры килүен нәтиҗәле тикшереп торуны оештырырга, моның өчен торак-коммуналь хезмәтләргә түләүләр исәпләве дөреслеген тикшереп тору блогы булган Бердәм исәп-хисап үзәге төзергә.

5. Җылылык энергиясен тотуның максималь күләме 0,2 Гкал/с ким булган йортлардан тыш («Энергияне саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы), бөтен күпфатирлы йортларга җылылык энергиясен тотуны исәпкә алуның гомумйорт приборларын урнаштырырга.

6. Идарәче компанияләрнең хуҗалык һәм финанс эшчәнлеген тикшереп торуны билгеләү максатында түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:

Россия Федерациясе Торак кодексы белән кертелгән күпфатирлы йортлар советы институтын үстерергә;

күпфатирлы йортлар советлары рәисләрен укытырга һәм аларга түбәндәге хокуклар бирергә:

язгы һәм көзге тикшерүләр нәтиҗәләре буенча күпфатирлы йортларның техник торышы актларына кул кую; гомуми милекне тоту һәм аңа ремонт ясау буенча эшләр планын килештерү (гомуми кулланылыштагы урыннарны җыештыру, йорт янындагы территорияне җыештыру, агымдагы һәм капиталь ремонт һ.б. буенча); гомуми милекне тоту һәм аңа ремонт ясау буенча эшләнгән эшләр актларына кул кую.

7. Бердәм исәп-хисап үзәген идарәче компанияләр йогынтысыннан чыгарырга, моның өчен «Бердәм исәп-хисап үзәге» республика дәүләт предприятиесе төзергә.

8. «Бердәм исәп-хисап үзәге» дәүләт предприятиесендә казначылык системасына охшаган исәпләүләр системасын гамәлгә ашырырга, торак-коммуналь хезмәтләргә түләү өчен керә торган барлык акчаларны «аерганнан» соң счетларның түбәндәге 3 төркеменә күчерергә:

йортларга идарә иткән өчен – идарәче компания счетына, идарәче компания акчалар керү белән үк бу счетка идарә итәргә мөмкин;

торак хезмәтләре өчен – подрядчы оешмалары счетларына, подрядчылар бу счетлардан идарәче оешма белән эшләнгән эшләр актына кул куйганнан соң гына файдалана алачаклар;

бирелгән коммуналь хезмәтләр өчен – ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар счетларына, оешмалар бу счетлардан идарәче оешма белән тикшерү актына кул куйганнан соң гына файдалана алачаклар.

9. Күпфатирлы йортлар советларына бюджет ярдәм итү механизмын эшләргә.

10. Милекчеләр һәм идарәче оешмалар мәнфәгатьләре балансын үтәү кирәклеген исәпкә алып, күпфатирлы йортларга оптималь идарә итү предметына бер идарәче оешма, торак милекчеләре ширкәте, торак-төзелеш кооперативы яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы составындагы бер идарәче оешмага аудит үткәрергә.

11. Гамәлдәге министрлык составындагы торак-коммуналь хуҗалыгы блогын һөнәри кадрлар белән көчәйтеп һәм аларның санын арттырып, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгын ныгытырга.

12. Халыкка торак-коммуналь хезмәтләргә түләү өчен бирелә торган субсидияне халыкның бурычлары исәбенә турыдан-туры коммуналь комплекс оешмаларына җибәрү мәсьәләсен өйрәнергә.

13. Коммуналь хезмәтләр буенча бурыч түләнгәнче, фатирлар сату-алу килешүләрен теркәмәскә, түләмәүчеләр фатирларында гражданнарны теркәүне тыярга.

14. Индивидуаль исәпкә алу приборларын җитештерүчеләргә зур төгәлсезлек җибәрә торган «А» һәм «В» класслы счетчиклар чыгаруны тыярга.

Өч ел эчендә индивидуаль исәпкә алу приборларын TRP тибындагы сыйфатлырак приборларга алмаштырырга.

15. Һәрбер шәһәрдә Торак-коммуналь хуҗалыгы департаментын булдырырга, аңа барлык коммуналь, хезмәт күрсәтү предприятиеләрен һәм оешмаларын, идарәче оешмаларны һәм торак милекчеләре ширкәтләрен буйсындырырга. Торак-коммуналь хуҗалыгы департаментларын үз чиратында муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларына буйсындырырга.

16. Ресурсларны саклау турында законнар Россия Федерациясе Торак кодексына тәңгәлләштерелергә тиеш. Тоту нормативлары һәрбер күпфатирлы йортның индивидуаль (проект, эксплуатация) үзенчәлекләре нигезендә һәр йорт өчен исәпләнергә



тиеш. Нормативлар уртача булмаска тиеш һәм яшәүче (теркәлгән) гражданнар санына бәйле булмаска тиеш.

17. Идарәче оешмаларга базар мөнәсәбәтләрендә тулысынча катнашу хокукы бирелергә тиеш. Идарәче оешмалар энергия ресурсларын халыкка ваклап сату бәясе белән сату хокукына ия булырга тиеш. Ресурслар өчен түләүләрне һәм җыемнарны оештыру эшләрен башкару чыгымнары РСОга түләнергә яисә ресурсның бәясенә кертелергә тиеш. Идарәче оешмаларга ресурс белән тәэмин итүче оешмалардан күпләп сату бәяләре буенча ресурслар күләмнәрен сатып алу мөмкинлеген тәэмин итү зарур.

18. Ресурслар белән тәэмин итүче һәм идарәче оешмаларның үзара эшчәнлек итүнең бердәм регламентын техник планда да, шулай ук финанс ягыннан да эшләргә кирәк.

19. Кулланылган ресурсларны исәпкә алуның бердәй стандартлары кирәк. Мәсәлән, хәзерге вакытта күләмнәрне исәпкә алу идарәче оешмалар көче белән, йортларның җылылык пунктларында урнаштырылган исәпкә алу приборлары ярдәмендә башкарыла, җылылыкны куллану объектына кадәр транспортировкалагандагы югалтулар күләме идарәче оешмаларга билгеле булмаган формулалар ярдәмендә исәпләп чыгарыла.

20. «Тәэмин ителә торган ресурсның (хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфаты» төшенчәсе тәэмин итүче өчен дә, кулланучы өчен дә төгәл билгеләнергә тиеш.

21. Торак фондын тотуга тарифлар икътисадый нигезләнгән һәм зыянсыз булырга тиеш. Халык үз торак фондын тотарга өйрәнергә тиеш. Намуссыз түләүчеләр өчен җаваплылык дәрәҗәсе билгеләнергә тиеш. Халыкка вакытында түләгән өчен кызыксындыру һәм түләмәгән өчен җәза бирү процедуралары тәкъдим ителергә тиеш.

Ресурслар өчен тарифлар үтә күренмәле һәм халыкның көче житәрлек булырга тиеш.

22. Муниципаль предприятиеләргә һәм дәүләт катнашындагы предприятиеләргә торак фондына идарә итү һәм аны тоту мәсьәләләре белән турыдан-туры шөгыльләнергә рөхсәт бирергә кирәк. «Пилот» мәйданчыгы буларак аеруча проблемалы участокны, мәсәлән, Казан шәһәрендәге Вахитов районын, алырга тәкъдим итәбез. Аның мисалында без тәкъдим ителгән һәм уңай нәтиҗәләр биргән эш схемасының нәтиҗәлелеген күзәтә алабыз. Мәсәлән, Казан юлларын төзекләндерү һәм тоту өлкәсендә.

Эксперимент үткәрү өчен федераль законнарга төзәтмәләр кертү зарур, беренче чиратта, МУПлар турындагы Законга,

ТКХны реформалауга ярдәм итү фонды турындагы Законга һәм башкаларга.

23. Халыкның һәм идарәче оешмаларның тәэмин итүчеләр алдындагы, түләнүе шикле булган бурычларын юкка чыгару турында, тәэмин итүчеләрнең һәм подрядчыларның хезмәт күрсәтүләре өчен һәр пункт буенча җыелган акчалар күләмендә түләү турында карарлар кабул итәргә кирәк.

24. Россия Федерациясе Торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының идарәче оешмалар эшчәнлеген лицензияләү турындагы инициативасын хупларга.

25. Йортлар буенча дифференциацияләнгән тарификация практикасын кертергә: йорт буенча күпме акча җыелган булса, аңа шулкадәр акча сарыф ителергә тиеш. «Зыянга» эшләүче күпфатирлы йортларны субсидияләү механизмын эшләргә.

26. Коммуналь инфраструктура предприятиеләрен финанслау буенча республика дәрәҗәсендә максатчан программалар кабул итү зарур.

27. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү һәм халыкны торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү максатларында муниципаль унитар предприятиеләр төзергә.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 98. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышын 2014 елның 13 февралендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 6 феврале
№ 3309-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 99. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы Лаеш суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
2. Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча 10 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. «Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 519-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).
4. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 529-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).
5. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 540-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
6. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 549-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
7. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 559-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
8. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 568-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 569-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 560-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 562-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 563-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 573-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 550-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 570-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның $16^{6}$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 572-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

17. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 567-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 577-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

19. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 564-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).



20. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында.

21. «Татарстан Республикасы Әтнә районы территориясендә торак пункт – Яңа Әтнә авылын төзү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

22. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.

23. «Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертү хакында.

24. «Татарстан Республикасы законнары җыелмасын бастырып чыгару буенча республика комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

25. Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында доклад.

26. Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының 2013 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында хисабы.

27. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законның 11 статьясына үзгәреш кертү хакында» 390485-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясендә вакытлыча яшәүче чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга карата Россия Федерациясенең аларга вакытлыча яшәү рөхсәт ителгән субъектында гына яшәү мөмкинлеге буенча билгеләнгән чикләүне бетерү турында).

28. «Азартлы уеннарны законсыз оештырган һәм уздырган өчен җаваплылыкны көчәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 318436-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.31 һәм 8.32 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 391503-6 номерлы федераль закон проекты турында (урманнарда санитария һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылыкны көчәйтү турында).

30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 393165-6 номерлы федераль

закон проекты турында (автобусларда пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салу өлешендә).

31. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясына балигъ булмаганнарның ата-аналары яисә башка законлы вәкилләренең балигъ булмаганнарны карап тоту, тәрбияләү, укыту, аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәреш кертү хакында» 398424-6 номерлы федераль закон проекты турында.

32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 421419-6 номерлы федераль закон проекты турында (донор каны белән эш йөртү өлкәсендә законнарны бозган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында).

33. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында.

34. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасы турында.

35. «Россия Федерациясеннән чыгу һәм Россия Федерациясенә керү тәртибе турында» Федераль законның 15 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Магадан өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

36. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 415556-6 номерлы федераль закон проекты турында.

37. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $14^1$, $15^1$ һәм $16^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 421486-6 номерлы федераль закон проекты турында.

38. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 150 статьясына үзгәреш кертү турында» 415703-6 номерлы федераль закон проекты хакында (фәнни тикшеренүләр өчен кертелә торган чыгым материалларын өстәлгән бәягә салымга салым салынудан азат итү өлешендә).



39. «Почта элемтәсе турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү хакында» 418752-6 номерлы федераль закон проекты турында.

40. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 46 һәм $179^4$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

41. «Ветераннар турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү турында» 401840-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе сәламәтлек саклау системасында сугыш ветераннары өчен госпитальләр структурасын саклап калуның өстәмә гарантияләре турында).

42. «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 418883-6 номерлы федераль закон проекты турында (ата-анасы билгеле булмаган балаларга туендыручысын югалткан очракта социаль пенсиягә хокук бирү хакында).

43. «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 420241-6 номерлы федераль закон проекты турында (ата-анасы билгеле булмаган балаларга туендыручысын югалткан очракта социаль пенсиягә хокук бирү хакында).

44. «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмурт Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

45. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына дәүләт җир күзәтчелеген камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 421545-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

46. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль законның $19^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Рязань өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

47. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 12 һәм 20 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Саха (Якутия) Республи-

касы Дәүләт Собраниесенең (Ил Тумэн) закон чыгару инициативасы турында.

48. «Этиль спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукцияне җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 415028-6 номерлы федераль закон проекты хакында (этил спиртын һәм алкоголь продукциясен оешманың бер аерым бүлекчәсе тарафыннан җитештерүне тыюны төгәлләштерү өлешендә).

49. «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 421531-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт кадастр бәяләвен камилләштерү өлешендә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 6 феврале
№ 3310-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 100. 2014 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру буенча чараларның якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

2014 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру буенча чараларның якынча планын расларга (төп нөсхәгә кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 6 феврале
№ 3312-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 101. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан куелган мәсьәләләр буенча, хисап бирү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының $190^2$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат төркемнәреннән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында мәсьәләләр исемлеген Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 6 феврале
№ 3313-IV ДС

2014 елның 6 февралендәге
3313-IV ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге**

1. Региональ салымнар буенча бирелгән ташламалардан файдалану нәтиҗәлелеге турында.

2. Халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтүдән кергән бюджеттан тыш акчалардан медицина оешмалары тарафыннан файдалану нәтиҗәлелеге турында.

3. 2012 – 2013 елларда республикада гамәлгә кертелгән яңа сәнәгать производстволарының региональ икътисадка тәэсире турында.

4. 2013 елда республикада булдырылган яңа югары җитештерүчән эш урыннары турында, аларны эшче кадрлар белән тәэмин итү һәм перспективада белгечләрне һөнәри әзерли торган яңа производстволар булдыру хакында.

5. Республика энергетикасын модернизацияләү чаралары турында.

6. Татарстан Республикасында урта сыйныф хәленең күрсәткечләре динамикасы турында.

7. Татарстан Республикасында кече һәм урта бизнесның чагыштырма йогынтысын арттыру чаралары турында.

8. Торак-коммуналь хуҗалыкның хәле һәм перспективалары турында, куллану нормаларын, нормалар буенча, нормалардан арткан тарифларны камилләштерү турында.

9. Сәламәтлек саклау өлкәсендә амбулатор-хастаханә буыны учреждениеләре турында. Хастаханәләргә һәм амбулаторияләргә капиталь ремонт ясау, аларны җиһазлар белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү чаралары турында. Тиешле республика программасын раслау мөмкинлеге турында.

10. Сәламәтлек саклау учреждениеләрен медицина кадрлары белән тәэмин итү проблемасы турында. Медицина хезмәткәрләрен социаль яклау чаралары турында, шул исәптән



балаларны мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына урнаштыру өлешендә.

11. Авыл җиренә килгән яисә эшкә күчкән барлык яшь белгечләргә, авыл җирендә кимендә биш ел эшләү шарты белән, торак төзүгә (сатып алуга) берәр миллион сум бирү перспективалары турында.

12. Орфан (сирәк очрый торган) һәм онкологик авырулар белән авыручы гражданнарны дарулар белән тәэмин итү проблемасы турында. Аны хәл итү өчен күрелә торган чаралар турында. Татарстан Республикасы бюджетыннан мондый чараларны финанслау күләмен киләсе елларга арттыру мөмкинлеге турында.

13. Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фонды 2018 елның 1 гыйнварына кадәр эшли, ләкин 2013 елдан гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү программасы буенча финанслау күләме һәм шуны нәтиҗәсендә яшәүчеләре күчереләчәк мәйдан да азая бара. Мәсәлән, 2013 елда ул 639,8 мең кв. м булса, 2014 елда бары тик 141,5 мең кв. м тәшкил итәчәк.

Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фондыннан киләчәктә ул эшләячәк чорда Татарстан Республикасының акча алу перспективалары нинди һәм республикада юкка чыгарылган авария хәлендәге торак фонды күләмнәре буенча 2018 елның 1 гыйнварына фаразлар нинди.

14. Күпбалалы гаиләләрнең балалар балигъ булу яшенә җиткәннән соң торак шартларын яхшыртуга чиратлары саклану һәм киләчәктә гаиләнең бергә яшәүче әгъзаларының фактагы составыннан чыгып торак белән тәэмин итү турында (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары).

15. Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен, шул исәптән күпбалалы гаиләләрне (өч баласы булган) җир кишәрлекләре белән тәэмин итү өчен, шулай ук социаль ипотека программасы буенча һәм арендага бирелә торган торак төзү өчен җирләр резервлау турында.

16. Социаль торакка ихтыяҗы булган гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү чаралары турында (чиратта торучыларны торак белән тәэмин итү, социаль торак төшенчәсен арендага бирелә торган торакка алмаштырмыйча социаль торак төзү).

17. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак һәм мөлкәт хокукларын бозуларны профилактикалау эшенең нәтиҗәлелеге турында.

18. Татарстан Республикасында «Уңайлы мохит» программасын гамәлгә ашыру турында. Коррекцияле мәктәпләрне ремонтлауны һәм җайланмалар белән җиһазлауны (шул исәптән лифтлар куюны) финанслауны арттыру мөмкинлеге турында.

19. Төбәк агросәнәгать комплексының конкурентлылык дәрәҗәсен, аеруча азык-төлек җитештерүне арттыру чаралары турында.

20. Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү республика максатчан программасын дәүләт планлаштыруы, дәүләт заказы һәм гарантияләнгән бәядән гарантияле урнаштыру принципларында эшләү турында, шул исәптән:

– өстәмә эш урыннары булдыру өчен авыл җиренә инвестицияләр кертүне стимуллаштыру турында, бу хакта Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турында еллык юлламасында әйтелде;

– җирле авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә ярдәм итүгә юнәлтелгән чаралар турында;

– Идел алды авыллары, районнары (Апас, Буа, Югары Ослан, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш) социаль-икътисадый үсештә артта калганга күрә, республиканың әлеге зонасын үстерү буенча республика ярдәмче программаларын кабул итү мөмкинлеге турында;

– авыл хуҗалыгы продукциясен сату өчен республиканың торак пунктларында махсуслаштырылган агропарклар, авыл хуҗалыгы базарларын ачу тәҗрибәсе турында, кулланучылар кооперациясен алга таба үстерүне стимуллаштыру хакында;

– Татарстан Республикасында нәселле терлекчелекне һәм кошчылыкны торгызу, республикабызны яхшыртылган җирле терлек һәм кош токымнары белән тәэмин итү чаралары турында;

– мелиорация системасын торгызу турында;

– Татарстан Республикасында җитештерелгән товарларга имидж ярдәмен күрсәтүгә (социаль реклама рәвешендә) юнәлтелгән мәгълүмат сәясәте турында;

– җитештерелә торган авыл хуҗалыгы продукциясенең һәм аны эшкәртүдән алган продуктларның сыйфатын тикшереп торуны көчәйтү турында.

21. Бакчачылык, дача һәм яшелчәчелек коммерциясез ширкәтләргә дәүләт ярдәменең республика максатчан программасын эшләп бетерү һәм кертү турында.



22. Татарстан Республикасы юлларында юл-транспорт һәлакәтләрен һәм үлем очракларын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.

23. Яшьләр арасында наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендә күрелә торган чаралар турында.

24. Гражданнарга түләүсез юридик ярдәм системасын үстерү чаралары турында.

25. Татарстан Республикасында мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын һәм керешүен тәэмин итү.

26. Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү буенча республика программасын кабул итү сроклары турында.

27. Халыкка экологик хәл турында мәгълүмат бирү системасын үстерү өчен күрелә торган чаралар турында.

28. Республикадагы демографик хәлгә йогынты ясый торган начар экологик хәл турында (табигый бала табуларның саны кимү, кесарев кисүе юлы белән бала табуларның артуы, йөклелек өзелү проценты, аеруча иртә срокларда, арту).

29. Гомуми файдалану урыннарында яшел үсентеләрне яклауга юнәлтелгән чаралар турында.

30. Социаль-мәдәни өлкәнең гамәлдәге учреждениеләрен (китапханәләрне, музыка һәм сәнгать мәктәпләрен, музейларны, мәдәният йортларын һәм сарайларын) капиталь ремонтлау программасын кабул итү мөмкинлеге турында.

31. Халык сәнгать һөнәрләрен һәм кәсепләрен саклап калу һәм үстерү турында.

32. Этник туризмны үстерү турында, аңа түбәндәгеләр кирә: милли-мәдәни һәм фольклор бәйрәмнәре; этнографик объектлары һәм махсус программалары булган музейларга һәм музей-тыюлыкларга баруны үз эченә алган туристлык маршрутлары; этнографик элементлар кулланып экскурсия программалары.

33. Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәте концепциясен гамәлгә ашыру турында.

34. Татарстан Республикасында Мәдәният елы кысаларында мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту, аларны квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү һәм мәдәният өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында.

35. Шәһәр төзелеше һәм җир законнары таләпләре нигезендә чикләрне тасвирлау һәм раслау зарурлыгына бәйле рәвештә муниципаль берәмлекләрнең чикләрен билгеләү турында Татарстан Республикасының аерым законнарына үзгәрешләр кертү хакындагы закон проектларын эшләүне төгәлләү чаралары

һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү турында.

36. Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә еллык юлламасында җирле үзидарә системасын камилләштерү буенча яңгыраган тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру турында.

37. Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә, шул исәптән дәүләт граждан хезмәткәрләренә, хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү чаралары турында.

38. Хезмәтне саклау өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыру проблемалары һәм әлеге өлкәдә җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү мөмкинлеге турында.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 102. Н.В. Вәлитованы Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнүгә тәкъдим итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы дәүләт үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге баш белгече Вәлитова Наталия Владимировнаны Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнүгә тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 6 феврале
№ 3314-IV ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 103. 2014 елның 27 февралендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттан тыш утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттан тыш утырышын 2014 елның 27 февралендә 8.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 26 феврале
№ 3397-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 104. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның 27 февралендәге чираттан тыш утырышы каравына кертелүче мәсьәлә турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның 27 февралендәге чираттан тыш утырышы каравына «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының (парламентының) Кырым Автономияле Республикасы халыкларына мөрәҗәгате турындагы» мәсьәләне кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 26 феврале
№ 3398-IV ДС

# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘЛӘРЕ

## 105. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**В.П. Строеваны**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең**
**Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы эшләр идарәсенең чараларны гамәлгә ашыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшчәнлек бүлеге башлыгы Валентина Петровна Строеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 9 гыйнвары
№ 1-РК

## 106. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**И.Г. Ганиевны**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең**
**Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ комбинатының генераль директоры Ганиев Илшат Газыйм улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 10 гыйнвары
№ 5-РК



## 107. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Г.В. Аристованы**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең**
**Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Российская газета» редакциясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Казан шәһәрендәге филиалы редакторы Галина Вячеславовна Аристованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 гыйнвары
№ 6-РК

## 108. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Д.Х. Бачуринаны**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең**
**Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Интерфакс-Поволжье» мәгълүмат агентлыгының үз хәбәрчесе Бачурина Диана Хөсәен кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 гыйнвары
№ 7-РК

## 109. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Р.Р. Мөкминовны**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең**
**Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен «Петербург – Бишенче канал» телерадиокомпа-

ниясе» ААҖ Иделбуе хәбәрчеләр бюросының үз хәбәрчесе Мөкминов Равил Ривкать улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 13 гыйнвары
№ 8-РК

## 110. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### К.Г. Садриевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Дәүләт төзелешенә зур өлеш керткән һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратында озак еллар аяусыз хезмәт куйган өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты җитәкчесе Садриев Камил Гайнетдин улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 15 гыйнвары
№ 12-РК

## 111. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### Ф.Ә. Илдарханованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография фәнни-тикшеренү үзәге директоры Илдарханова Флюра Әмир кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 15 гыйнвары
№ 13-РК



## 112. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### А.И. Зыятдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Мамадыш муниципаль районының Усалы авыл җирлеге башлыгы Зыятдинов Альмир Имаметдин улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 15 гыйнвары
№ 14-РК

## 113. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

### А.Ш. Зыятдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, техник фәннәр докторы, профессор Зыятдинов Азат Шәймулла улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 15 гыйнвары
№ 15-РК

## 114. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт советы депутаты В.Н. Липужина тарафыннан кертелгән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 568-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (муниципаль хезмәткә бәйле чикләүләр исемлеген тулыландыру, вазыйфаларны төгәлләштерү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тоту таләпләрен билгеләү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 568-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2014 елның 13 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 15 гыйнвары
№ 17-РК



## 115. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Р.Т. Мансуровны
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең
Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен «Юл йөрү куркынычсызлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Мансуров Ришат Тәлгать улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 17 гыйнвары
№ 18-РК

## 116. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**О.Н. Дмитриеваны
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең
Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге әйдәүче белгече Ольга Николаевна Дмитриеваны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 17 гыйнвары
№ 19-РК

## 117. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Т.А. Барсукованы**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең**
**Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе Татьяна Анатольевна Барсукованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 17 гыйнвары
№ 20-РК

## 118. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 570-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасын мәгълүматлаштыру программасының төшенчәсен билгеләү, шулай ук терминологиягә һәм сылтама нормаларын федераль законнарга тәңгәлләштерү өлешендә) алдан карау турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 570-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик



экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты күрсәтелгән закон проектын 2014 елның 13 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 17 гыйнвары
№ 21-РК

## 119. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**А.Ш. Зыятдиновны**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең**
**Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының дәүләт корылышы, социаль-икътисадый һәм мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Зыятдинов Азат Шәймулла улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 18 гыйнвары
№ 22-РК

## 120. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары В.Н. Липужина һәм Н.Н. Рыбушкин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 569-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату очраклары исемлеген арттыру өлешендә) алдан карау хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 569-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын 2014 елның 13 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 20 гыйнвары
№ 23-РК



## 121. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Д.М. Гыйсметдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының мәгълүмат-аналитика эше буенча рәис урынбасары Гыйсметдинов Дамир Минсәгыйрь улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 гыйнвары
№ 26-РК

## 122. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**А.Р. Әһлетдиновны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Наркотиклар әйләнешенә контроль идарәсе оператив хезмәте башлыгы урынбасары Әһлетдинов Альберт Равил улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 гыйнвары
№ 27-РК

## 123. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Р.М. Ситдыйковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Наркотиклар әйләнешенә контроль идарәсе оештыру-инспектор бүлегенең махсус йөкләмәләр буенча өлкән инспекторы Ситдыйков Рамил Мансур улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 гыйнвары
№ 28-РК

## 124. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Е.Ю. Филимонованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясе Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Наркотиклар әйләнешенә контроль идарәсе махсус элемтә бүлегенең баш белгеч-эксперты Елена Юрьевна Филимонованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 21 гыйнвары
№ 29-РК



## 125. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Р.Ф. Дәүләтшинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау үсешенә зур өлеш керткән өчен «2 нче Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хирургия бүлеге табиб-хирургы Дәүләтшин Руберт Фәсах улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 23 гыйнвары
№ 32-РК

## 126. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**К.В. Замараевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Тикшерү комитеты тикшерү идарәсенең аеруча мөһим эшләрне тикшерү буенча икенче бүлекнең мөһим эшләрне тикшерүчесе Константин Васильевич Замараевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 23 гыйнвары
№ 33-РК

## 127. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**В.А. Новиковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Тикшерү комитеты тикшерү идарәсенең Бөгелмә районара тикшерү бүлеге җитәкчесенең өлкән ярдәмчесе Владимир Александрович Новиковны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 23 гыйнвары
№ 34-РК

## 128. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**М.Р. Нугаевны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга зур өлеш керткән өчен Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Тикшерү комитеты тикшерү идарәсенең гражданнарны кабул итү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге җитәкчесе Нугаев Марат Рәшит улын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 23 гыйнвары
№ 35-РК



## 129. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 571-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау турында (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларын «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми хокукый мәгълүмат сайты»нда урнаштыру (бастырып чыгару) хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 571-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты күрсәтелгән закон проектын 2014 елның 21 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 24 гыйнвары
№ 36-РК

## 130. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**О.А. Шалдыбинаны
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең
Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Җирле үзидарә үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ольга Анатольевна Шалдыбинаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 24 гыйнвары
№ 38-РК

## 131. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**В.П. Оленинны
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең
Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Җирле үзидарә үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге башлыгы Владимир Павлович Оленинны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 24 гыйнвары
№ 39-РК



## 132. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Торак төзелешен үстерүгә ярдәм турында» Федераль законның $16^{6}$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 572-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау хакында (Законның эконом класс торагын төзү максатларында Фондның җир кишәрлекләрен бирү белән бәйле нигезләмәләрен һәм башка нигезләмәләрен «Торак төзелешен үстерүгә ярдәм турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 23 июлендәге 239-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Торак төзелешен үстерүгә ярдәм турында» Федераль законның $16^{6}$ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 572-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты күрсәтелгән закон проектын 2014 елның 13 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 24 гыйнвары
№ 40-РК

# 133. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексының 135[7] статьясына үзгәреш кертү турында» 574-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (җитештерүле аучылык контролен гамәлгә ашыру өлешендә) алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 135[7] статьясына үзгәреш кертү турында» 574-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты күрсәтелгән закон проектын 2014 елның 24 мартына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 29 гыйнвары
№ 46-РК



# 134. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ш.Ш. Яһудин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 573-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын (түләүсез юридик ярдәм алуга хокуклы гражданнар исемлеген арттыру турында) алдан карау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 87 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 573-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына, аны закон проекты буенча җаваплы итеп билгеләп, депутат берләшмәләренә, шулай ук юридик экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсенә җибәрергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты күрсәтелгән закон проектын 2014 елның 13 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан беренче укылышта карауга әзерләргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 29 гыйнвары
№ 47-РК

## 135. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**О.Л. Улемнованы**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының рәсем һәм декоратив-фәнни сәнгать бүлеге әйдәүче фәнни хезмәткәре Ольга Львовна Улемнованы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 29 гыйнвары
№ 48-РК

## 136. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Р.Н. Салиеваны**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану институтының җир асты байлыкларыннан файдалануның һәм экологиянең хокукый проблемалары лабораториясе мөдире Салиева Роза Наил кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 29 гыйнвары
№ 49-РК



## 137. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Г.Г. Садыйкованы**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Апас муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Апас районы территориаль бүлеге җитәкчесе Садыйкова Гөлнара Гыйлемхан кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2014 елның 30 гыйнвары
№ 51-РК

## 138. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ КҮРСӘТМӘСЕ

**Г.Х. Насыйбуллинаны**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләү турында**

Апас муниципаль районының мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен Апас муниципаль районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган Апас урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Насыйбуллина Гөлнур Хәйдәр кызын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хаты белән бүләкләргә.

